БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

ЖОМГА
27
ДЕКАБРЬ
1940 ел.
№ 300 (6100)
Аерым номеры 10 тиен.

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ,
ШӘҺӘР КОМИТЕТЫ,
ТАССР ВЕРХОВНЫЙ
СОВЕТЫ ҺӘМ ШӘҺӘР
СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

КОЛХОЗ БРИГАДИРЫ

Колхозларда иген уңышы өчен көрәшү, хезмәтне оештыру, хезмәт өчен түләү, социалистик хезмәт дисциплинасын ныгыту, хезмәткә намус белән карашны булдыру, звеноларга җитәкчелек итү һәм башка мәсьәләләр буенча колхоз бригадирларына йөкләтелгән бурычлар аеруча җаваплы һәм катлаулы. Авыл хуҗалыгы артеленең уңышлы эшләве, башлыча, әнә шушы төп кадрларның, колхоз производствосы командирларының ничек эшләүләренә бәйләнгән.

Бригадир эшлекле һәм политик яктан тотнаклы булса производство бригадаларында тәртип була, бригаданың эшләре вактында башланалар һәм яхшы нәтиҗәләр белән төгәлләнеп чыгалар. Ленин—Сталин партиясе һәм Совет хөкүмәте колхозлар өчен аерата әһәмиятле булган бу кадрларны сайлап алуга, аларны үстерүгә, тәрбияләүгә һәр вакыт зур игтибар итәләр. ВКП(б) Үзәк Комитеты үзенең 1932 нче ел 4 нче февральдә кабул иткән карарында ук инде „**Бригадирларны сайлап алу, алар составындагы еш алмашынучанлыкны бетерү һәм аларның хуҗалык һәм политик яктан квалификацияләрен күтәрүдә аларга чын-чынлап ярдәм итү партия оешмаларының иң әһәмиятле бурычлары булып торырга тиешләр**“ диде. Бу, партия оешмалары өчен әле дә үтә актуаль бурыч булып кала.

Колхоз бригадирлары составы даими булу бик мөһим нәрсә. Бригадир булып озак эшләүче кеше үз бригадасындагы һәрбер кешенең характерын да, нинди эшкә сәләтле булуын да, нинди эшне яратуын да, нәрсә белән кызыксынуын да, кемнең кем белән килешеп эшли алуын да, хәтта аларның семья тормышларын һәм көнкүреш ихтиаҗларын да яхшы белә. Боларны белү бригадир өчен исә бик кирәк, чөнки ул иртән таңнан алып кичке караңгыга кадәр колхозчылар янында эшли, ул җәй көннәрендә болыннарда, кырларда колхозчылар белән бергә кунып эшләүче, аларга җитәкчелек итүче кеше.

Колхоз бригадиры—ул иген уңышын күтәрү өчен һәм терлекчелекне үстерү өчен колхозчылар массасын оештыручы, **звеноларга турыдан-туры җитәкчелек итүче кеше.** Димәк, колхоз бригадиры югары иген уңышының иң яхшы мастеры булырга, агрономия белеме белән сугарылган һәм агротехника чараларын үткәрү өчен көрәшүче кеше булырга тиеш. Моның өчен партия райкомнары һәм җир бүлекләре бригадирлар өчен агрозоотехника семинарларын оештырырга, бригадирларның белемнәрен күтәрергә тиешләр. Бригадирның колхоз хуҗалыгында белмәгән эше булмаска тиеш. Бригаданың бөтен эше өчен ул тулы җаваплы. Аннан соң колхозчы эш буенча да, үзенең шәхси мәсьәләләре буенча да иң элек бригадирына мөраҗәгать итә. Ә бригадир андый вакытта аптырап калмаска, бәлки үзенең эше һәм киңәше белән үрнәк күрсәтергә, үзенең авторитеты белән йогынты ясарга тиеш.

Колхоз бригадиры—ул, үз бригадасының эшен план белән һәм большевистик тәртип белән алып барырга тиеш. Бригадир карамагына беркетелгән атлар тук булсын, арба-чаналар, сбруйлар, авыл хуҗалыгы машиналары анда-монда ташланып ятмасын өчен бригадир яхшы хуҗалыкчы кеше булырга тиеш. Шунсыз бригадирның эше зәгыйф була, гомуми артель хуҗалыгына зур зиан килә, колхозчыларда социалистик милеккә коммунистик карашны тәрбияләү эше кыенлаша. Бригада хуҗалыгында тәртип урнаштыру, ул, әлбәттә, киң магнәле нәрсә. Сүз арба-чаналарны, сбруйларны һәм машиналарны таркатып яткырмау турында гына түгел, бәлки бу нәрсәләрнең һәрбер бригадада да җитәрлек булуларына ирешү турында, сүз арба турында кыш көне, чана турында җәй көне үк алдан кайгырту, хезмәт көннәрен хезмәт кенәгәләренә вактында язып бару һ.б. турында бара. Бригадир боларның һәрберсе турында даими рәвештә кайгыртып торырга тиеш.

Бездә эшлекле, сәләтле, авторитетлы бригадирлар—колхоз производствосының чын командирлары, иген уңышы мастерлары меңәрләп саналалар. Мисаль өчен менә иптәш Гатаулла Гайнуллин. Ул Әтнә районы, Киров исемендәге колхозда 1932 нче елдан бирле бригадир булып эшли. Аның бөтен эше план белән алып барыла. Һәрбер эшне колхозда алдынгы булып үти. Үз эшен тәмам иткәч башка бригадаларга социалистик ярдәм оештыра. Аның һәрбер эш участкысында тәртип һәм чисталык, пөхтәлек. Ул җитәкчелек итә торган 9 нчы бригада быел бөртекле культуралар буенча һәрбер гектардан 15,45 центнер уңыш алды. Яки менә Буа районы „Коминтерн“ колхозының бригадиры иптәш Бакиров Әхмәт. Ул 4 елдан бирле бригадир. Аның бригадасында иген уңышы өчен көрәш тирәсенә барлык кешеләре тупланган. Эш нормасын үтәмәүче бер генә колхозчы да юк. Колхозчылар бригадир киңәшеннән читкә чыкмыйлар. Бригадир зур авторитет белән файдалана. Мондый бригадирларны һәрбер районнан, һәрбер колхоздан диярлек табып була.

Колхозларның еллык отчет маглүматларына караганда, Татарстанда 1940 нчы ел башына 12.464 кырчылык бригадиры булган. Шулардан бригадир булып 1 елдан ким эшләүчеләре 5.205 кеше булса, ә өч елдан артык стажлылары бары 2.377 кеше генә санала, хатын-кыз бригадирлар 644 тән дә артмый. Бу саннар кырчылык бригадирларының яртылашы яшь кадрлар булуны, аларның составы еш алмашынып торуны һәм колхозларда зур көч булган хатын-кызларның бригадирлар составында бик аз булуларын күрсәтәләр. Район партия комитетлары, башлангыч партия оешмалары һәм җир органнары бу ике төп кимчелекне бетерү өчен конкрет чаралар күрергә, бригадирларны тәрбия итү эшен көчәйтергә, аларны перчатка шикелле алмаштырып торуга чик куярга тиешләр. Колхоз председательләренең бригадирлар өстеннән җитәкчелекләре — бригадирларга көндәлек эштә ярдәм итүдән, бригадирлар инициативасын вактында эләктереп алудан, бригадирлар игтибарын дәүләт йөкләмәләрен вактында үтәүгә юнәлдерүдән гыйбарәт булырга тиеш. Колхозчыларга бригадир биргән бойрыкны, ул биргән нарядларны кайбер председательләр тарафыннан бригадирдан башка юкка чыгару, шуның белән эшкә таркату кертү, бригадирларны санга санамау кебек зарарлы практиканы бетерергә кирәк.

Без яңа елга керәбез. Алда зур бурычлар тора. Партиянең XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясен колхозлардагы һәрбер бригаданың зур уңышлар белән каршылавы өчен алар арасында социалистик ярышны оештыру һәм киң күләмдә җәеп җибәрү партия райкомнарының һәм җир органнарының мактаулы бурычлары булып тора.

ВКП(б) ның Бөтенсоюз Конференциясе хөрмәтенә

Мамадыш районының хезмәт ияләре партиянең XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясе чакырылу турындагы хәбәрне зур рухлану белән каршы алдылар. Предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә партиянең XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясен производстводагы яңа уңышлар белән каршылау өчен конкрет йөкләмәләр алына.

Еллык планны 30 нчы ноябрьгә үтәгән „Швейпром“ артелендә булган җыелышта Конференция ачылу көнен беренче квартал производство планын үтәү белән каршылау турында бердәм рәвештә карар кабул ителде.

Урман кисүдә һәм ташуда эшләүчеләр арасында ярыш киң җәелдерелә. Ворошилов исемендәге колхозның утын ташучылар бригадасы (Ошма урман пунктында) Конференциянең ачылу көненә кадәр 28 ат белән 4.600 кубометр утын ташырга йөкләмә алды.

* * *

ЗЕЛЕНОДОЛЬСК, 26 декабрь. Зеленодольск шәһәренең предприятиеләрендә ВКП(б) ның XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясе исемендә социалистик ярыш җәелдерелә. Начальниклары Чечнев һәм Бровкин булган цехларның коллективлары (М. Горький исемендәге завод) 1941 нче елның январь һәм февраль айлары планын 110 процент итеп үтәргә йөкләмә алдылар. (ТатТАСС).

Язу машиналары заводы стахановчысы-фрезеровщица иптәш М. Махмудова. Ул планын ай саен 150 процентка үтәп килә. С. Сабирҗанов фотосы.

ВКП(б) НЫҢ XVIII НЧЕ БӨТЕНСОЮЗ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ХӨРМӘТЕНӘ МАССОВЫЙ СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШНЫ ҖӘЕЛДЕРИК

Татарстан АССР промышленностеның барлык эшчеләренә, инженер-техник работникларына һәм хезмәткәрләренә

(МЕХКОМБИНАТ ПРЕДПРИЯТИЕЛӘРЕ ЭШЧЕЛӘРЕНЕҢ, ИНЖЕНЕР-ТЕХНИК РАБОТНИКЛАРЫНЫҢ ҺӘМ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ХАТЫ)

Кадерле иптәшләр!

Безнең чәчәк атучы Ватаныбызны производство һәм политик активлыкның куәтле яңа дулкынчы чолгап алды. 1941 нче елның 15 нче февралендә партиянең XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясе чакырыла дигән хәбәрне күп миллионлы совет халкы гаять зур шатлык белән каршы алды, бу хәбәр барлык хезмәт ияләрендә бу гүзәл вакыйгане халык хуҗалыгының барлык фронтларында җиңүләр белән истә калдырырга тыелгысыз омтылыш тудырды. Промышленность һәм транспорт алдынгылары социалистик предприятиеләрнең уңышларын арттыралар, еллык программаны срогыннан алда тәмам итәләр, Ватан файдасына үз-үзләрен аямыйча хезмәт итү үрнәкләре күрсәтәләр.

Партия оешмаларының промышленность һәм транспорт өлкәсендәге эшләре турындагы мәсьәләне хәл итү өчен җыелачак XVIII нче Бөтенсоюз - Партконференциясе хөрмәтенә социалистик ярыш Советлар Союзының фабрикаларында, заводларында, тимер юлларында көннән-көн киңәя.

Сталинчыл өченче бишьеллыкта СССР Промышленносте ВКП(б) ның тарихи XVIII нче Съезды карарларын үтәгән хәлдә, гаять зур уңышларга ирешә. Бу эштә СССР Верховный Советы Президиумының шушы елның 26 нчы июнь, 10 нчы июль һәм 10 нчы август карарлары зур роль уйнадылар. Алар, хезмәт дисциплинасын ныгытуның һәм хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүнең куәтле этәргече буларак, предприятиеләргә продукция эшләп чыгаруны арттырырга, аның сыйфатын яхшыртырга, промышленностьның һәм илебезнең бөтен халык хуҗалыгының тагын да үсүен тәэмин итәргә, Ватаныбызның оборона сәләтен тагын да ныгытырга мөмкинлек бирделәр. Болар барсы да совет халкын яңа батырлыкларга, бөек Ленин—Сталин эшенең тулы тантанасы өчен үз-үзенне аямыйча көрәшүгә рухландыралар.

Сталинчыл өченче бишьеллык планны үтәү өчен көрәштә Татарстанның мех промышленносте да җидди уңышларга ирешә. 1, 2 һәм 4 нче фабрикаларның, 5 нче номерлы механика заводының, мәктәп—фабриканың коллективлары үзара ярышып, еллык программаны срогыннан алда үтәделәр. Бездә хезмәт җитештерүчәнлеге планга карата 104,8 процент булды, продукциянең үзенә төшү бәясе 11 ай эчендә 1939 нчы елга чагыштырганда 2,33 процент кимеде. Мех промышленносте 11 ай эчендә дәүләт сумаларына 90.771 мең сум экономия ясады.

Без, Казан мехкомбинаты эшчеләре, инженер-техник работниклары һәм хезмәткәрләре киләсе елны тагын да зуррак җиңүләр яулап алуны, еллык программаны сан һәм сыйфат күрсәткечләре буенча срогыннан алда—1941 нче елның 20 нче декабренә үтәүне өстебезгә алабыз. ВКП(б) ның XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясен лаеклы рәвештә каршылауны оештырып, без 1941 нче елның ай ярымлык программасын 12 нче февральдән соңга калмыйча үтәрбез. Планнан тыш, үзгәрми торган бәяләр белән, 888,5 мең сумлык өстәмә продукция бирербез, шул исәптән:

41.000 данә сарык тиресе, 21.700 данә тряска, 21.700 данә яка, 8.850 данә бүрек, 10 тонна май һәм 6 тонна йон бирербез.

1940 нчы елга чагыштырганда һәрбер эшченең эшләп чыгарышын 15 процентка арттырырбыз, продукциянең үзенә төшү бәясен 1,5 процентка киметербез. Январь аенда 75 тонна ягулыкка һәм 25.000 киловатт-сәгат электр энергиясенә экономия ясарбыз.

Өстебезгә алган йөкләмәләрне уңышлы үтәү өчен без фабрикалар, цехлар һәм аерым работниклар арасында социалистик ярышны җәелдерербез. СССР Верховный Советы Президиумы Указларын тайпылышсыз рәвештә тормышка ашырырбыз, хезмәт дисциплинасын барлык чаралар белән ныгытырбыз, хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да арттырырбыз, югары сыйфатлы продукция эшләп чыгаруны тәэмин итәрбез. Технология нормаларыннан берниндиә дә читкә китүләргә юл куймабыз, фабрикаларда технология процессларын тагын да яхшырту өчен бөтен көчебезне бирербез.

Без Татарстандагы барлык предприятиеләрнең эшчеләрен, инженер-техник работникларын һәм хезмәткәрләрен чакырабыз:

— Партиянең XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясе хөрмәтенә социалистик ярышка кушылыгыз! Барыбыз да бер кешедәй булып, бердәм һәм оешкан төстә эшлик, Ватаныбызның байлыгын арттырыйк, социалистик Ватанның куәтен тагын да ныгытыйк!

Яшәсен Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе—җиңүләребезне оештыручы һәм рухландыручы!

Яшәсен хезмәт ияләренең бөек юлбашчысы, тирән акыллы җитәкчебез—Иосиф Виссарионович **Сталин!**

(Мөраҗәгат мехкомбинатының 6.000 эшче, белгеч һәм хезмәткәр катнашкан гомуми фабрика митингларында кабул ителде).

ЗУРЛАРНЫ УКЫТУ ЯХШЫ БАРА

Апас районының Кече Әтрәч авылында укый-яза белмәүче 19 кеше, аз белемле 59 кеше һәм рус графикасы нигезендәге татар алфавитын өйрәнергә тиешле 70 кеше бар иде. Алар һәммәсе дә 1 нче октябрьдә укуга тартылдылар. Укый-яза белмәүчеләрдән 16 кеше хәзер аз белемлеләрне укыту курсына күчерелде. 80 кеше аз белемлеләр курсын һәм рус графикасы нигезендәге татар алфавитын укыту курсын тәмам итеп чыкты.

Хәзерге көндә бу авылда укый-яза белмәүче 3 кеше, аз белемле 35 кеше калды. Без хәзер бу иптәшләрне 1 нче январьга грамоталы итеп чыгару өчен көрәшәбез. Культармеецлардан Абушаева, Якупова һәм Сафина иптәшләр аеруча яхшы эш үрнәкләре күрсәтәләр.

Ә. Мөбарәкшин.

ТАССР ның КРАЙНЫ ӨЙРӘНҮ ҮЗӘК МУЗЕЕНЕҢ 45 ЕЛЛЫГЫ

Татарстан АССР ның Крайны Өйрәнү Үзәк Музее работниклары коллективына

ВКП(б) Өлкә Комитеты һәм Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы Татарстан АССР ның Крайны Өйрәнү Үзәк Музее работниклары коллективын музейнең яши башлавына 45 ел тулу уңае белән чын күңелдән котлыйлар.

45 ел эчендә Татарстан АССР ның Крайны Өйрәнү Үзәк Музее краебызның тарихын һәм материаль культурасын өйрәнү һәм хезмәт ияләре арасында популярләштерү эшендә зур эш эшләде.

ВКП(б) Өлкә Комитеты һәм Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы, Татарстан АССР ның Крайны Өйрәнү Үзәк Музее коллективының хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү бурычларын тормышка ашыру буенча, социалистик культураны үстерү буенча киләчәктә дә уңышлы эшләячәгенә ышаныч белдерәләр.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты.
Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы.

* * *

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Крайны Өйрәнү Үзәк Музееның работниклар коллективын музейнең 45 еллыгы уңае белән чын күңелдән котлый.

Крайны Өйрәнү Үзәк Музее, үзе яши башлаганнан бирле, краебызның тарихын, табигый байлыкларын өйрәнү эшендә һәм хезмәт ияләре массасының культурасын күтәрүдә күп уңышларга иреште.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Крайны Өйрәнү Үзәк Музееның киләчәктә дә социалистик культураны үзләштерүдә хезмәт ияләренең ышанычлы ярдәмчесе булачагына ышана.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы.

* * *

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты Татарстан АССР ның Крайны Өйрәнү Үзәк Музееның фән работниклары һәм хезмәткәрләре коллективын музейнең 45 еллык юбилее уңае белән котлый.

Музей яши башлаганнан бирле 45 ел эчендә һәм бигрәк тә социалистик революция елларында җирле крайны өйрәнү һәм краебызның тарихын киң катлау хезмәт ияләре массасы арасында популярләштерү буенча гаять зур эш эшләде.

ВКП(б) Шәһәр Комитеты музейнең фән работниклары һәм хезмәткәрләре коллективының, шәһәр һәм республика хезмәт ияләре белән якын элемтәне ныгытуда дәвам итеп, киләчәктә дә җирле крайны, аның табигый байлыкларын, җитештерүче көчләрен, эшчеләрнең һәм хезмәт иясе крестьяннарнең азатлык өчен революцион көрәшләре тарихын өйрәнү буенча иҗади эшне җәелдерүгә үзенең барлык көчләрен һәм энергиясен бирәчәгенә, краебызның данлыклы тарихи үткәнен масса арасында киң күләмдә популярләштерәчәгенә һәм шулай итеп коммунистик җәмгыят төзеп җиткерүдән гыйбарәт булган бөек эшкә хезмәт итәчәгенә ышаныч белдерә.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты.

Агитация-масса эшләре көчәйде

СССР Верховный Советы Президиумының 2 нче декабрь Указы буенча Минзәлә сайлау округыннан Милләтләр Советына бер депутат сайланырга тиеш.

Бу Указ чыгу белән без Калинин районының Иске Сәфәр авылында барлык хезмәт ияләренең катнашы белән митинглар үткәрдек. Митингларда 400 дән артык кеше катнашты. Чыгып сөйләүче иптәшләр СССР Верховный Советы Президиумының Указын бердәм рәвештә яхшы дип таптылар.

19 нчы декабрьдә барлык сайлаучыларның гомуми җыелышлары үткәрелде. Бу җыелышларда участкы сайлау комиссияләренең составына кандидатлар билгеләнде. Безнең авыл күләмендә ике сайлау участкысы төзелә. Аларның эшләүләре өчен билгеләнгән биналар яхшы итеп җиһазландырылды һәм комиссияләрнең нормаль эшләүләре өчен барлык шартлар тудырылды.

Безнең партия оешмасы янында 21 кешедән торган агитаторлар коллективы бар. Бу коллектив сайлау кампаниясен уңышлы рәвештә үткәрү өчен эшкә кушылды. Агитаторларның иң зур күпчелеге үткән сайлаулар вактында агитатор булып эшләгән иптәшләр. Без аларны колхоз бригадаларына беркеттек. Алар бригадаларда җыелышлар үткәрделәр, СССР Верховный Советына сайлаулар турындагы положениеләрне сайлаучыларга өйрәттеләр һәм хәзер СССР Конституциясе турында беседалар үткәрәләр. ВКП(б) Өлкә Комитетының соңгы пленумы карарлары да барлык бригадаларда аңлатылды. Шуның нәтиҗәсендә колхозда язгы чәчүгә хәзерлек эшләре шактый яхшырды. Шушы 3—4 көн эчендә 350 гектар мәйданда кар тотылды, кырга 650 йөк тирес чыгарылды, чәчүлек орлыкларны чистарту эше яхшырды. Иптәш Миргазиан Шәрипов җитәкчелек итә торган 3 нче бригада аеруча яхшы эшли.

Колхозда дәүләт йөкләмәләренең үтәлеше дә яхшы бара. Безнең авыл советы буенча еллык финанс планы 116 процент үтәлде. Колхоз фермалары дәүләткә ит, сөт һәм йон тапшыру йөкләмәләрен 100 процент итеп үтәделәр.

Авылда зурларны укыту эше дә шактый алга бара. 3 нче бригадада агитатор булып эшләүче укытучы иптәш Фатыйма Якупованың тырышып эшләве нәтиҗәсендә 19 кеше рус графикасы нигезендәге яңа алфавитны өйрәнде. Башка бригадаларда да зурларны укыту шактый яхшырды. Бригадаларда үткәрелгән җыелышларда колхозчылар язгы чәчүгә большевистик хәзерлекне тәэмин итү өчен үз өсләренә конкрет йөкләмәләр алдылар.

Шуның белән бер рәттән колхозда күп кенә җитешсезлекләр дә бар әле. Иптәш Сабирҗан Билалов җитәкчелегендәге 1 нче бригадада язгы чәчүгә хәзерлек эшләре бик начар тора. Бригадада хезмәт дисциплинасы начар оештырылган. 2 нче һәм 4 нче бригадаларның да эшләре канәгатьләнерлек түгел. Бу җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерергә кирәк.

З. Исмагыйлов.

Калинин районының Иске Сәфәр авылындагы башлангыч партоешма секретаре.

ЯШЕЛЧӘДӘН МУЛ ДОХОД

Әтнә районының Киров исемендәге колхозында 12 гектар яшелчә һәм 4,3 гектар җиләк-җимеш бакчасы бар. Дәүләт иптәш Хәлимуллин 1930 нчы елдан бирле яшелчәчелек бригадиры булып эшли. Ул үз эше белән нык кызыксына. Яшелчәдән мул уңыш алу буенча күп кенә тәҗрибә эшләре алып бара.

Колхозда быел соң утыртыла торган кәбестәнең һәр гектарыннан уртача 400 центнер уңыш алынды. Иптәш Шәрәфиева звеносында иртә утыртыла торган кәбестәнең һәр гектарыннан уртача 200 центнер уңыш чыкты.

Колхоз үткән ел яшелчә сатудан 38 мең сум доход алган иде. Быел бу доход 100 мең сумга җитә. Ләкин колхоз хуҗалыгының бу тармагында кимчелекләр дә бар әле. Яшелчә участкысына тирес чыгару эше бик начар бара. Колхоз правлениесе яшелчәчелек бригадасын тарту көчләре белән тәэмин итүгә салкын карый.

Х. Шәрәфиев.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

ПАРТИЯ ОЕШМАСЫ ҺӘМ ЯШ КОММУНИСТЛАР

Татарстан Финанс Халык Комиссариаты янындагы башлангыч партоешма соңгы ике елда шактый үсте һәм ныгыды. Шушы вакыт эчендә ВКП(б) члены итеп 12 кеше һәм ВКП(б) членлыгына кандидат итеп 19 кеше кабул ителде. Алар — производство алдынгылары һәм җәмагат эшендә актив катнашучы иптәшләр.

Мисаль өчен яш коммунист Тимерхановны алыйк. Ул 1936 нчы елны районда инспектор булып эшли иде. Соңыннан наркомат аппаратына җаваплы эшкә күтәрелде. Ул җитәкчелек итә торган ревизия составы зур уңышларга ирешә. Үткән елның ахрында иптәш Тимерханов аппараттагы иң зур бүлекнең— штатлар бүлегенең җитәкчесе итеп күтәрелде. Элек бу бүлекнең эшендә шактый кимчелекләр бар иде. Аңа иптәш Тимерханов җитәкчелек итә башлаганнан соң бүлекнең эше сизелерлек дәрәҗәдә яхшырды. Иптәш Тимерханов производствода яхшы эшләү белән бергә, үзенең политик белем дәрәҗәсен күтәрү буенча да тырышып эшли. Ул хәзер „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнүне тәгәлләп килә. Үз бүлегендәге работниклар арасында политик - тәрбия эшләре алып бара, һәр атнага бер тапкыр беседа (эчке яки халыкара хәлләр турында) үткәрә. Шулай ук бүлектә регуляр рәвештә производство киңәшмәләре җыела.

1939—40 нчы елларда партиягә кабул ителгән яш коммунистлар безнең оешмада учетта торучы коммунистларның 40 процентын тәшкил итә. Аларны тәрбияләү эше—оешманың зур бурычларыннан берсе булып тора. Оешма бу эшнең төп формасы итеп алар белән беседалар үткәрүне һәм аларга партия поручениеләре бирүне алды. Поручениеләр, кемнең нинди эшне башкарырга сәләтле булуыннан чыгып биреләләр.

Иптәш Альмешев массовый оборона эшләренә җитәкчелек итә. Иптәш Әюпов агитколлективка җитәкчелек итә. Фролова һәм Иксанова иптәшләр Осоавиахим оешмасына җитәкчелек итәләр. Бу иптәшләр үзләренә бирелгән эшләрне намус белән үтиләр. Партия оешмасы поручениеләрнең үтәлешен системалы рәвештә тикшереп тора. Поручениеләрне ничек үтәүләре турында коммунистларның отчетлары тыңлана. Бу — коммунистларның дисциплиналылыкларын тагын да ныгыта, җаваплылык сизүләрен күтәрә.

Күптән түгел партия җыелышында коммунистларның производстводагы авангардлыклары турында наркомның доклады тыңланды. Докладчы алдынгылар һәм артта баручылар турында кызыклы фактлар китерде. Бу мәсьәләне тикшерү эштәге тәҗрибәләрне уртаклашу белән бәйләп алып барылды. Шул ук вакытта аерым коммунистлар эшендә булган кимчелекләр тәнкыйть ителде. Чыгып сөйләүче иптәшләр администрация һәм партбюро алдына күп кенә таләпләр куйдылар, социалистик ярышка җитәкчелекне көчәйтергә, тәҗрибәләрне уртаклашу эшен юлга салырга кирәклекне күрсәттеләр. Җыелыш, яш коммунистлар өчен зур мәктәп булды. Алар бу җыелыштан сон үзләренең рольләрен тагын да яхшырак аңлап эш итә башладылар.

Я. Байбурин.

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА

ВКП(б) Өлкә Комитеты карары буенча түбәндәге кешеләр ВКП(б) сафларыннан чыгарылдылар:

Насыйбуллин А. Н. (Партия билеты № 1629840)—һәр вакыт эчеп йөргән һәм прогул ясаган өчен. **Зарипов М. З.** (партия билеты № 3272942)—һәр вакыт эчеп йөргән һәм прогул ясаган өчен. **Катаев А. И.** (кандидатлык карточкасы № 1296708)—һәр вакыт эчеп йөргән, исерек хәлендә кандидатлык карточкасын югалткан һәм хезмәттәге хәленнән үз интересына файдаланганы өчен. **Таланов А. И.** (партия билеты № 3756844)—партия билетын икенче тапкыр югалткан һәм ялган документ ясаган өчен. **Романов И. К.** (партия билеты № 2946139)—партия билетын югалткан һәм хулиганлык өчен. **Минеев Ш. Н.** (партия билеты № 1637821)—партия һәм дәүләт дисциплинасын бозган өчен. **Приданниксва А. С.** (партия билеты № 1748568)—прогул ясаган һәм социалистик милекне урлаган өчен. **Мулдагалиев Н. М.** (кандидатлык карточкасы № 0758617) — пассивлык өчен һәм партиягә членлык взносларын түләмәгән өчен. **Георгиев Т. Н.** (кандидатлык карточкасы № 1642665) — ВКП(б) сафларына очраклы төстә генә килеп кергән өчен. **Гоголева К. В.**(партия билеты № 1635532)—һәр вакыт эчеп йөргән һәм прогул ясаган өчен. **Камалов Т. К.** (партия билеты № 1628750)—эчеп йөргән һәм прогул ясаган өчен. **Перевозчиков Я. С.** (партия билеты № 1627731)—эчеп йөргән һәм прогул ясаган өчен. **Николаев К. Н.** (кандидатлык карточкасы № 3157746)—эчеп йөргән һәм прогул ясаган өчен. **Сәлимев Х. Ш.** (кандидатлык карточкасы № 3157755)—партиягә очраклы төстә генә килеп кергән өчен. **Лебедева А. Н.** (кандидатлык карточкасы № 1640741)—партиягә очраклы төстә генә килеп кергән өчен. **Смирнов К. Н.** (партия билеты № 1635790)—прогул ясаган һәм эчеп йөргән өчен.

Партработниклар өчен кичке уку

ВКП(б) ның Шөгер райкомы район үзәгендә эшләүче партработниклар өчен кичке укулар оештырды. Анда 35 кеше укый. Алар 1 нче апрельгә кадәр 7 нче класс программасы буенча рус теле, география, физика, математика фәннәрен үтәчәкләр. Укулар 5 көнгә ике тапкыр (4 әр сәгать) була.

5 занятие үткәрелде инде. Укучылар занятиеләрдә актив катнашалар. Дәресләргә район үзәгендәге урта мәктәпнең иң яхшы укытучылары җитәкчелек итә.

В. Хәлимов.

„ВКП(б) ТАРИХЫНЫҢ КЫСКАЧА КУРСЫ“ НИЧЕК ТӨЗЕЛДЕ

„Ленинградская правда“ ның 251нче номерында иптәш Ем. Ярославскийның 1940 нчы елның 1 нче октябрендә партиянең Ленинград шәһәр оешмасы активы җыелышында ясаган докладының кыскартылган стенограммасы басылып чыкты. Докладның исме: „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ ның әһәмияте һәм пропагандист эшенең бурычлары“.

„ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ ның ничек төзелгәнлеге турында сөйләп иптәш Ярославский болай дигән:

„Эш шактый озак барды. Партия Үзәк Комитетына дәреслекнең бер-бер артлы дүрт варианты тәкдим ителде. Ләкин алар барсы да яраксыз дип табылдылар. Иптәш Сталин, партия тарихының һәрбер аерым моментын большевистик теориягә бәйләргә кирәк диде һәм эшкә үзе тотынды. „Кыскача курс“ ны төзү өстендә ул 4 ай эшләде. Иптәш Сталин, партиябезнең тормышында һәрбер этапны Маркс—Энгельс—Ленин теориясе ягыннан карап тулырак һәм тирәнрәк яктыртырга омтылып, бөтен марксизм-ленинизм әдәбиятын актарып чыкты.

Эш барышында иптәш Сталин бездә Маркcның һәм Энгельснең күп кенә әсәрләренең бик начар тәрҗемә ителгәнлеген күрде. Бер үк әсәрнең төрле тәрҗемәләрендә җидди аермалар һәм ялгышлар бар. Шулай итеп, Маркс—Энгельс—Ленин Институты өчен киң эш мәйданы ачылды. Бу институт Марксизм классиклары әсәрләренең барлык тәрҗемәләрен тикшерү эшенә керешге.

Иптәш Сталин „Кыскача курс“ ны төзү эшен тәмам иткәннән соң, ул, китапның соңгы вариантын ВКП(б) Үзәк Комитетының Редакция Комиссиясенә җибәрде. Шуннан соң һәр көнне иптәш Сталин кабинетында берничәшәр сәгать рәттән, кай вакытларда төн уртасына кадәр, Редакция Комиссиясе членнары „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ ның һәрбер юлын җентекләп тикшереп чыктылар.

Мин үземнең партия эшем башланганнан бирле бик күп төрле редакция комиссияләре күрдем, ләкин эшкә иптәш Сталин тарафыннан булган кебек шундый тирән, таләпле, игтибарлы карашны бер кайчан да күргәнем юк иде, бер кайчан да очратканым юк иде.

Комиссия „Кыскача курс“ ны бүлекләп-бүлекләп карап үткәргән бу уникаль кич безнең һәрберебезнең хәтрендә гомерлеккә калыр. Иптәш Сталин һәрбер әйтелгән фикергә искиткеч игтибар белән карады. Ул „Кыскача курс“ та хәтта кечкенә генә ялгышлар да яки төгәл әйтелеп җитмәгән урыннар да булмау турында зур кайгыртучанлык күрсәтте.

Иптәш Сталинның „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ н төзү өстендә эшләве аның гаять зур теоретик эшенең бер өлеше генә.

Иптәш Сталин безгә большевикның ничек эшләргә тиешлеген күрсәтә. Мин уйлыйм, безнең партиябездә иптәш Сталин кебек практик эшләр белән күмелгән башка кеше юктыр. Шуңа да карамастан ул зур теоретик эш өчен вакыт таба, дәреслекләрне редакцияләү өчен дә вакыт таба. Ничек кенә редакцияләү әле! Иптәш Сталин „Кыскача курс“ның барлык бүлекләрен диярлек яңадан язып чыкты бит, ә күп кенә бүлекләрне, мәсәлән, дүртенче бүлекнең икенче бүлекчәсен ул бөтенләе белән үзе язды.

Партия тарихын өйрәнү өчен, теоретик эш өчен вакыт җитми дип әйтүчеләргә мин, Сталин вакыт таба икән, безнең һәрберебез теорияне өйрәнү өчен ике-өч өлеш күбрәк вакыт таба алачак дип әйтергә телим“.

(„Большевистская печать“ журналының 22 нче номерыннан).

Район газеталарыннан

— ВКП(б) райкомы бюросы үзенең утырышында күмер промышленностена эш көчләре җибәрүнең торышын тикшерде. Бюро, район буенча бу эшнең канәгатьләнмәслек торуын әйтеп, партия, комсомол оешмаларын эш көчләре туплаучыларга якыннан булышлык итәргә тәкдим итте.

(*„КОМУНАР“ газетасы, Чепья районы*).

— Парткабинетның көтепханәсендә 3.200 данә китап исәпләнә. Моннан бер ел элек парткабинетка аена күп дигәндә 100 кеше йөрсә, хәзер ай саен уртача 350 кеше йөри. 1939 нчы елның декабрь аенда укучылар кулында 128 китап булса, быел шул ук вакытка 220 китап укучылар кулында исәпләнә.

(*„КОЛХОЗ ЯРЫШЫ“ газетасы, Красный Бор районы*).

— Стена газетасы редакторлары һәм хәбәрчеләрнең район активы белән катнаш киңәшмәсе булды. Анда 200 кеше катнашты. Киңәшмә, ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Зайцевның „Хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү һәм стена газеталарының, хәбәрчеләрнең бурычлары“ дигән темадагы докладын тыңлады.

(*„КЫЗЫЛ ЗӘЙ“ газетасы, Заинский районы*).

— Шушы көннәрдә „Москва“ колхозында сораулар һәм җаваплар кичәсе үткәрелде. Кичәдә 100 гә якын сорауга комиссиянең членнары тарафыннан җаваплар бирелде. Колхозчылар, колхозчы хатын-кызлар һәм интеллигентлар кичәгә актив катнаштылар.

(*„ОКТЯБРЬ КОЛХОЗЧЫСЫ“ газетасы, Октябрь районы*).

МАТБУГАТ КҮЗӘТҮ

„Ударник Тавышы“ газетасы җәмагат терлекчелеген үстерү өчен начар көрәшә

(ВКП(б) ның Тәкәнеш райкомы һәм хезмәт ияләре депутатларының район советы органы)

Авыл районнарында игенчелек мәсьәләләре белән бер рәттән терлекчелек мәсьәләсе дә гаять зур әһәмияткә ия булып тора. Колхозларда җәмагат терлекчелеген үстерү өчен көрәшне һәм терлекчелек алдынгыларының эш тәҗрибәләрен уртаклашуны һәр яклап яктырту—район газеталары битләрендә киң урын алырга тиеш.

Менә безнең алда „Ударник Тавышы“ газетасы. Сүзне газетаның май аенда чыккан 50 нче номерыннан башлыйк. Бу номерда „Җәмагат терлекчелегенең торышы турында“ ВКП(б) райкомы һәм хезмәт ияләре депутатларының район советы карары басылган.

СССР Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карарын тормышка ашыру йөзеннән чыгып кабул ителгән бу карар, районда җәмагат терлекчелеген үстерүнең конкрет срокларын билгели. Шулай ук бу карарда: „Район газетасы редакторы иптәш Нуриевка терлекчелек алдынгыларының бай эш тәҗрибәләрен һәм шулай ук җәмагат терлекчелеген үстерү турындагы мәсьәләләрне район газетасында системалы рәвештә яктыртырга тәкдим итәргә“ диелә.

„Ударник Тавышы“ газетасы бу карарны үтәү өчен ничек көрәшә соң? Без шул сорауга җавап бирү өчен газетаның 47 номерын карап чыктык. Шушы 6 ай вакыт эчендә терлекчелек мәсьәләләре темасына 16 мәкалә һәм хәбәр урнаштырылган. Хәбәрләрнең эчтәлекләренә тукталганчы шуны әйтергә кирәк: газета терлекчелек мәсьәләләренә аз игтибар бирә. 47 номер газетага бары 16 гына хәбәр урнаштырылу гына да моны ачык күрсәтә.

Редакция терлекчелек мәсьәләләрен газетада яктыртуны планлы тәртиптә алып бармый. Үз агымы белән килгән хәбәрләрне урнаштыру белән генә чикләнә. Шуңа күрә хәбәрләрнең темалары да бер үк төрле була һәм алар бер яклы гына язылган булалар. Ә инде кайбер айларда бу турыда бер нәрсә дә язылмый. Бирелә төп җитешсезлек—терлекчелек эшендә эшләүче алдынгыларны, белгечләрне газета тирәсенә тартмауда. Соңгы 6 ай вакыт эчендә сыер саучыларның, терлек караучыларның һәм гомумән ферма җитәкчеләренең бер генә хәбәрләре дә урнаштырылмау әнә шуны күрсәтә. Дөрес, газетада урнаштырылган 16 хәбәрнең 8ен район җир бүлеге мөдире урынбасары Шәйхеттинов һәм өлкән зоотехник Фәтхуллина иптәшләр язганнар. Ләкин аларның бу хәбәрләре өстән генә язылган булганлыктан, сводка характерындагы коры саннардан һәм колхоз председательләре фамилияләрен санаудан гына гыйбарәт булып чыкканнар.

Районда терлекләр комплектовать итү планы 1940 нчы елның 1 нче апреленә атлар буенча 92 процент, мөгезле эре терлекләр буенча 72 процент, сарыклар һәм кәҗәләр буенча 57 процент үтәлгән булган. Шушы өзеклекне бетерүне күздә тотып, ВКП(б) райкомы һәм район советы башкарма комитеты карарында болай диелә: „Яңа фермалар оештыруны шушы елның 1 нче июненә тәгәлләргә, яңа оештырылган һәм элеккеге фермаларда терлекләр санын ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карарында күрсәтелгән минимум санга туры китереп комплектовать итүне 1 нче сентябрьгә тәгәлләргә...“ Бу директиваны үтәү өчен көрәштә район газетасы иң алдынгы сафта булырга тиеш иде. Ләкин без моны күрмибез. Редактор карарны бастыкан да, шуның белән тынычланган. Районда яңа фермалар оештыру һәм булганнарын комплектовать итү эше ничек тора? Моны газетадан карап белеп булмый.

„Ударник Тавышы“ газетасын укучы кешедә үзеннән-үзе бер сорау туа:—Тәкәнеш районында терлекчелек эше яхшы куелган колхозлар һәм терлекләрнең продуктлылыгын күтәрүгә ирешкән фермалар бөтенләй юкмы әллә? Без газетаның соңгы 6 айда чыккан номерларында бу сорауга җавап таба алмадык. Дәүләт өчен гаять әһәмиятле булган бу эшкә—җәмагат терлекчелеген үстерү мәсьәләсенә мондый гамьсез караш „Ударник Тавышы“ газетасының иң зур җитешсезлеге булып тора. Шуның белән бергә, бу факт ВКП(б) Үзәк Комитетының „район газеталары турында“гы карары нигезендә эшне үзгәртеп коруның гафу ителмәслек начар торуын күрсәтә.

„Ударник Тавышы“ газетасы үзенең бу җитешсезлеген тиз арада бетерергә, районда җәмагат терлекчелеген үстерү өчен системалы көрәш алып барырга тиеш. Терлекчелек алдынгыларын һәм белгечләрне редакция тирәсенә кинрәк тартырга, аларның хәбәрләренә һәм мәкаләләренә газета битләрендә киң урын бирергә кирәк. Шулай эшләгәндә газета үзенең эшен нәтиҗәле итеп куя алыр.

Пионерлар йортының уку залында (Казан). И. Галиев фотосы.

Кечкенә һәм зур тәртипсезлекләр турында

(Укучы балалар арасында тәрбия эшләренең куелышы мәсьәләсенә карата)

Моннан берничә ай элек „Яш Ленинче“ газетасында „Тәртипсезлек кенә түгел—җинаят“ дигән мәкалә басылып чыкты. Бу мәкаләдә—Кызыл Армия районындагы Акъяр тулы булмаган урта мәктәбе укучылары Гайсә Гафуровның һәм Рәшит Нуретдиновның совет балаларына хас булмаган чыгышлары турында язылган иде. Алар мәктәптә системалы рәвештә тәртип бозганнар, укытучыларына дәрес алып барырга уңайсызлаганнар, иптәшләренә дәрес тыңларга комачаулаганнар. Моның белән генә дә калмаганнар, мәктәптән тыш урыннарда да үзләрен начар тотканнар. Бер көнне алар 60 яшьлек карчыкның тәрәзәләренә пычрак атып, үзен әшәке сүзләр белән сүгеп киткәннәр.

Чыннан да алар тәртипсезлек кенә түгел—җинаят эшләгәннәр. Кешене кимсетү, хурлау, аның шәхесенә тию—җинаят булып санала. Ул илебезнең төп законы—Сталин Конституциясе буенча тыела.

Бу балалар үзләренең мондый чыгышлары өчен укытучылары һәм ата-аналары тарафыннан бик нык шелтәләнергә, укучылар массасы һәм җәмагатчелек тарафыннан каты тәнкыйть уты астына алынырга тиешләр иде.

Ләкин, кызганычка каршы, хәбәрченең язуына караганда, ул вакытта бу балаларга бер нинди дә чара күрелмәгән. Аларның чыгышларына гафу ителмәслек рәвештә салкын караганнар, игтибар итмәгәннәр.

Бу мәкалә „Яш Ленинче“ укучылары тарафыннан киң рәвештә тикшерелде һәм үзенә күп кенә откликлар алды. Мәкалә балаларны тәрбияләү эшендә булган зур бер кимчелек турында сөйли. Бу кимчелек совет укучысына хас булмаган чыгышлары өчен балаларны җавапсыз һәм җәзасыз калдырудан гыйбарәт.

Чынлап та безнең кайбер укытучыларыбыз һәм ата-аналарыбыз балаларны тәрбияләүдә бер яклы гына эш алып баралар, алар һаман да әле балаларны бары тик иркәләп, башларыннан сыйпап, ялынып-ялварып тәртипкә чакыру методын гына кулланалар. Гайсә һәм Рәшит белән дә шундый ук хәл булган булырга тиеш. Әгәр дә алар беренче тәртипсез чыгышларыннан соң ук ата-аналары, укытучылары һәм иптәшләре тарафыннан каты отпор алган булсалар, әбине мыскыл итүгә кадәр барып җитмәгән булырлар иде.

Әгәр дә зурлар совет гражданына хас булмаган начар чыгышлар ясыйлар икән, алар бөтен җәмагатчелек алдында җавап бирәләр, җәза алалар. Балалар—булачак гражданнар. Аларның да совет укучысына хас булмаган чыгышлары җавапсыз калдырылырга тиеш түгел. Булачак гражданнар үзләренең хокукларын һәм бурычларын хәзердән үк аңлый белергә, һәрбер чыгышлары өчен хәзердән үк җавап бирә белергә тиешләр.

Менә шуның өчен дә балаларның иң беренче һәм иң кечкенә булган яраксыз чыгышларын да игтибарсыз калдырмаска кирәк.

Кайбер ата-аналар һәм укытучылар арасында „ул мондый эшне беренче тапкыр гына эшли, моннан соң кабатламас“ дип тынычланучылар бар. Ә кайберәүләр „мондый кечкенә генә эш өчен баланы борчырга ярамый“ диләр.

Дөрес түгел. Гаепнең кечкенәсен эшләгән бала зурсын эшли алмыймени? Баланы кечкенә генә чыгышы өчен дә уйланырга, үкенергә мәҗбүр итәргә кирәк. Бу, гаепне икенче тапкыр кабатламаска яхшы була.

Кечкенә генә бер факт:

Казандагы 80 нче номерлы урта мәктәпнең икенче этаж коридоры буйлап бер укучы килә. Коридор яңа гына чистартылып, себерелеп чыгарылган. Идәндә бер генә дә чүп әсәре юк. Мәктәп җыештыручы апаның тырышып эшләгәне күренеп тора. Биек, якты, чиста коридор буйлап килүче әлеге укучы кесәсеннән нинди дер кәгазь ала да идәнгә ташлый. Укытучылардан берәү моны күрә, ләкин бер сүз дә әйтми. Бераз баргач теге укучы лач иттереп идәнгә төкерә. Укытучы бу юлы әйтми „түзми“, салкын гына итеп: „Идәнгә төкерергә ярамый“ ди.

Билгеле, болай дип кенә әйтү укучыга бер ничек тә тәэсир итми. Ул мондый сүзләрне генә күп ишеткән инде. Алар берсе дә аның йөрәгенә үтеп кермиләр, намусына тимиләр, дулкынландырмыйлар һәм борчымыйлар.

Әгәр дә укытучы шушы вакытта аны аерым бүлмәгә алып кереп, янына утыртып, аның белән чын күңелдән сөйләшкән булса, мәктәп җыештыручының хезмәтен хөрмәтләргә кирәклеген, һәрбер укучының мәктәп гигиенасын сакларга тиешлеген, гомумән, идәнгә төкерүнең культурасызлык икәнлеген яхшылап аңлаткан булса, балага бөтенләй башкача тәэсир иткән булыр иде. Укытучы аны, идәнгә ташлаган чүбен алып чүп савытына салырга, идәндәге төкреген сөртеп алырга мәҗбүр итсә, бала бер вакытта да мондый культурасызлыкны икенче тапкыр кабатламас, хәтта иптәшләрен дә мондый эшләрдән тыяр иде.

Ләкин без күбесенчә алай эшләмибез. Дәрес өзүче, тәртип бозучы, зурларга һәм иптәшләренә карата тупас мөгамәләдә булучы, мәктәп милкен җимерүче балаларга еш кына килешүчәнлек күрсәтәбез. Дисциплина—һәрбер эшнең үзәге. Дисциплина булган җирдә—уку сыйфаты күтәренке. Шуның өчен балалар арасында тәртипсезлеккә каршы, дисциплиналылык өчен көрәшне төрле яклап көчәйтергә кирәк.

Совет иленең иң яхшы педагогы А. С. Макаренко балаларны тәрбияләү методлары буенча гүзәл хезмәтләр калдырды. Макаренконың бу хезмәтләрен укытучылар да, ата-аналар да тырышып өйрәнергә, балаларны тәрбияләү эшендә алардан нык лап файдаланырга тиешләр.

Совет мәктәбе социалистик җәмгыятнең яңа кешесен тәрбияләргә тиеш. Балаларда кешедә була торган иң яхшы сыйфатларны—дисциплиналылыкны, намуслылыкны, турылыклылыкны, куркусызлыкны һәм кыюлыкны тәрбияләргә кирәк. Аларда хәзердән үк совет гражданының хисләре яшәсен. Алар хәзердән үк үзләренең чыгышларын аңлый һәм алар өчен җавап бирә белсеннәр.

М. Дибаева.

◆

Кадрлар хәзерләүгә начар карыйлар

Заинский МТС ы быел механик кадрлар хәзерләү планы буенча 60 лап кеше укытып чыгарырга тиеш. Ләкин бу көнгә әле, төрле курсларда бары 7 кеше укый. Трактор бригадирлары, комбайнчылар хәзерләү курсларына әле бер кеше дә җибәрелмәгән. МТС янында укырга тиешле 25 тракторчы өчен курсны башлап җибәрүгә хәзерлек эше дә бик акрын бара. Газогенераторлы ЧТЗ тракторларында эшләүчеләр хәзерләү буенча да бөтенләй эшкә керешмәгән. МТС, директоры Дьячин, директорның политик эшләр буенча урынбасары Гафуров иптәшләр механик кадрлар хәзерләү эшенә бөтенләй игтибарсыз карыйлар

Үзәк музейдә

(45 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕ БЕЛӘН)

Хезмәт ияләре массасын коммунистик тәрбияләү эшендә безнең илебездә музейләр зур урын алып торалар. Революция елларында бездә крайны өйрәнү буенча меңнәрчә өлкә һәм район музейләре, йөзләрчә художество, әдәбият музейләре төзелгән булу очраклы хәл түгел. Алар арасында Татарстан АССР ның Крайны Өйрәнү Музее беренче урыннарның берсен алып тора. Ул илебездәге өлкә музейләренең ин зурларыннан берсе. Анда 500 меңгә якын бик кыйммәтле экспонатлар җыелган. Музейнең экспонатлар урнаштыру өчен 7 мең квадрат метр чамасы зурлыкта мәйданы бар. Музейдә 20 гә якын фән работниклары эшли. Музейгә дәүләт ел саен шактый күп сумалар бирә. Үткән елны музейдә 129 мең, быел 100 мең чамасы экскурсант булды. Музейгә Советлар Союзының барлык почмакларыннан ел саен меңнәрчә туристлар килә. Монда алар экспонатлар залларында дүрт елга иленең—Татарстанның табигый байлыклары белән, элекке Казан губернасының—царизм колониясе булган крайның тарихы белән, крайда булган революцион хәрәкәт белән, бөек Лениннең Казандагы тормышы белән, В. И. Лениннең гүзәл шәкертләре булган С. М. Кировның, Я. М. Свердловның, В. М. Молотовның, шулай ук башка гүзәл кешеләрнең безнең шәһәребездә үткән тормышлары һәм революцион эшләре белән танышалар. Социалистик төзелеш бүлегендә экскурсантлар гражданнар сугышы, торгызу чоры һәм Сталинчыл беренче бишьеллыклар чорларының тәэсирләндерерлек документлары белән танышалар.

Большевиклар партиясе тарихын өйрәнүчеләр өчен ярдәмче буларак музей аеруча урын тота. Монда алар өчен бик күп материал бар. Ул Кереш бүлеге дип аталган бүлектә урнаштырылган. Анда җирнең тарихы, тереклекнең килеп чыгуы һәм үсүе, кешенең килеп чыгуы, Дарвин таглиматы күрсәтелә. Бу белемнәр Тарих бүлегендә аеруча тулы биреләләр.

Музейнен юбилеенә тарихчылар—музейнең фәнни сотрудниклары зур бүләк хәзерләделәр. Алар үткән йөзнең беренче елларыннан башлап 1917 нче елгы февраль революциясенә кадәр булган чорга карата крайның тарихы буенча бөтен материалларын бергә туплап урнаштырдылар. Монда Татарстанның гомуми тарихы буенча да тулы материал бирелә. Шулай итеп, партия тарихын өйрәнүчеләр һәм пропагандистлар хәзер музейдән зур ярдәм ала алалар.

Шулай ук музейдә социалистик төзелеш бүлегенең беренче дүрт темасын төзү эше дә төгәлләнде. Болар түбәндәгеләр: „Бөек Октябрь Социалистик Революциясен хәзерләү һәм үткәрү“, „Хәрби интервинция һәм гражданнар сугышы“, „Торгызу чоры“ һәм „Илне индустрияләштерү һәм авыл хуҗалыгын коллективлаштыру“. Музейнең фән работниклары коллективы ирешелгәннәр белән генә тукталып калмаячак һәм бу бүлекнең башка темаларын да төзүне дәвам иттереп, ачыла торган экспозицияләрне тагын да яхшыртачак.

Ләкин теге яки бу бүлекнең экспозициясен төзү генә җитми. Музей работниклары бу куелган материаллар тирәсендә зур күләмдә пропаганда-масса эше алып барырга тиешләр. Музейдә дә, шулай ук музейдән тышта да политик агарту эше алып баруга аеруча игтибар бирелә. Бу эшнең формалары бик күп төрле. Монда хезмәт ияләренең аерым группаларының, студентларның, мәктәп балаларының музейгә массовкаларын оештыру да, киң күләмдә лекция эшләре алып бару да керә. Якын араларда музейдә җирле крайның тарихы турында, Казанда торган атаклы кешеләрнең тормышлары турында, Казандагы тарихи-архитектура памятниклары турында лекцияләр циклы башланачак. Музей буенча берничә радио-экскурсияләр үткәрергә билгеләнә. Күргәзмәләр оештыру эше киңәйтелә. Быел уннан артык зур күргәзмәләр оештырылачак. Мәсәлән, „В. М. Молотовның тормышы һәм революцион эше“, „Москва һәм Ленинград художникларының эшләре“, „Промышленность торакларын тизләтелгән методлар белән төзү“, „Татарстан АССР ның XX еллыгы“ һ. б. Хәзер музей татар халык сәнгате күргәзмәсен, иң күренекле совет художникларының автолитографияләре күргәзмәсен, балалар уенчыгы күргәзмәсен һ.б. оештыра. Без күргәзмәләрне музейдә оештыру белән генә чикләнмибез. Кайбер күргәзмәләрне район музейләрендә дә оештырабыз. Хәзер Казан тимер юлында вагон-клубта күргәзмә оештыруга хәзерлек башланды.

Музей мәктәп балаларына хезмәт күрсәтү буенча зур эш үткәрә. Музейдә укучылар өчен экскурсияләр генә түгел, бәлки чын дәресләр дә үткәрелә. Бу дәресләрдә музей экспонатларыннан киң күләмдә файдаланыла. Шушындый экспонатларның мәктәп кабинеты фондларына аерып куелган шактый өлеше мәктәпләрдә дәрес алып бару өчен бирелә. Быел шундый экспонатларны Казан мәктәпләренең меңнән артык укытучылары сорап алдылар.

Билгеле, музейнең эшендә күп кенә кимчелекләр дә бар әле. Аларның иң зурысы—җирле крайны, бигрәк тә аның җитештерүче көчләрен фәнни яктан тикшерү эшенең йомшак куелуы. Крайны массовый өйрәнү эше әле башлангыч хәлдә генә. Ул, башлыча музей эчендә генә алып барыла. Шуның өстенә башка кайбер кимчелекләр дә бар, ләкин музей сотрудниклары коллективы бу кимчелекләрне кыска срок эчендә бетерергә омтылалар һәм бетерерләр. Республиканың партия һәм совет органнарының, бөтен җәмагатчелекнең игтибары моңа ярдәм итәр.

В. Дьяконов.

Музейнен гыйлми секретаре.

ЧИТ ИЛЛӘРДӘ

ФРАНЦИЯНЕҢ ЭЧКЕ ХӘЛЕ ТУРЫНДА ГЕРМАНИЯ ГАЗЕТАСЫ

БЕРЛИН, 25 декабрь. (ТАСС). „Мюнхенер нейесте нахрихтен“ газетасы Франциянең эчке политик хәленә багышланган мәкалә урнаштырды.

Газетаның язуына караганда, Франция дәүләтенең хәзерге формасы бары тик бу дәүләтнең яңа эчтәлеге өчен үзенең артында көрәш бара торган ширма гына. Лавальдән, Марсель Деадан, Дориодан, Маркедан һәм башкалардан тора торган политик эшлеклеләр группасы үзенең бурычы итеп „яңа Европага кушыла алырлык“ Франция төзүне куя. Ләкин алар үзләренең эшләрендә Франциянең кайбер политик даирәләренең каршылыгына очрыйлар. Хәзерге вакытта Парижда „Эвр“ газетасын чыгаручы Марсель Деа Виши хөкүмәтенең кайбер тенденцияләренә каршы чыга. Петэнның авторитетлы режимын саклап калу өчен бердәм партия төзү планы җимерелгәннән соң Марсель Деа бу тенденцияләрне артка таба атланган бер адым дип саный.

Франциядә „ике ялгышу“ күренә. Беренче ялгышу шуннан гыйбарәт: кайберәүләр Франциянең җиңелүен онтырга яки бу факт белән хисаплашмаска тырышалар. Ләкин бу нәрсә мөмкин түгел. Солых төзү Франциянең хәлен бары тик „ул яңа Европада үз урнын таныса гына“ беркадәр яхшыртачак. Ләкин бу мәсьәләдә Франция тарафыннан сүз түгел, бәлки эш кирәк һәм бу хәлне аеруча күрсәтеп торуның кирәге юк.

Икенче ялгышу Урта диңгездәге вакыйгаләр нәтиҗәсендә килеп чыкты. Беренче ялгышуга азмыкүпме кушыла торган кешеләрдә шулай ук Италиянең ике фронтта чигенүе күчәр державаларының Англиягә каршы көрәшләрендә көчләр чагыштырмасын инде үзгәртте дип санийлар.

Мәкаләнең ахрында газета болай дип яза:—бу фактлар „Франциядә нинди политик группаларның яңа Европа идеяләренә кушылуларын һәм нинди группаларның бу эшне бары тик тактик карашлардан чыгып кына эшләүләрен“ билгеләргә мөмкинлек бирделәр. Соңгы атналарда Англия пропагандасы Франциядә Германия кыенлыкларга очрый башлады дип әйтүе белән ялгыша. Кыенлыклар турында сүз дә булырга мөмкин түгел, „чөнки нинди генә кыенлыкны да берничә сәгат эчендә бетерү өчен безнең бер приказ бирүебез дә җитә“.

Англия—Германия сугышы

ГЕРМАНИЯ ХӘБӘРЛӘРЕ

БЕРЛИН, 25 декабрь. (ТАСС). Германия информация бюросы Германия армиясе верховный командованиесенең түбәндәге сводкасын тапшыра: „23 нче декабрьдә булган сугыш хәрәкәтләре вакытында Германиянең торпеда катерлары дошманның 2.500 регистр брутто-тонна авырлыктагы тагын бер сәүдә карабын батырдылар. 24 нче декабрьгә каршы төндә Манчестерны уңышлы рәвештә бомбага тотканнан соң Германия авиациясе 24 нче декабрьдә дә, 25 нче декабрьгә каршы төндә дә бернинди дә һөҗүмнәр ясамады. Шулай ук дошман самолетлары да Германия территориясе өстендә күренмәделәр“.

АНГЛИЯ ХӘБӘРЛӘРЕ

ЛОНДОН, 25 декабрь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 25 нче декабрьгә каршы төндә Англия территориясенә һавадан бер һөҗүм дә ясалмаган.

Шул ук вакытта, 18 нче декабрьдә төнлә тәмам булган атна эчендә Англия авиациясенең Италиянең 68 самолетын бәреп төшергәнлеге һәм үзенең 10 истребителен югалтканлыгы хәбәр ителә. Италия сугышка кушылганнан бирле Англия авиациясе Италиянең барлыгы 385 самолетын бәреп төшергән һәм аэродромнарда 158 самолетны юк иткән.

АМЕРИКА ХӘБӘРЛӘРЕ

НЬЮ-ЙОРК, 25 декабрь. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 24 нче декабрьгә каршы төндә Германия авиациясе озак вакыт буена Ланкаширны бик нык бомбага тоткан. Күп кешеләр корбан булган.

Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәренә караганда, Канаданың баш министре Кинг Англиядә генерал-майор Макнаутон командасында Канаданың армия корпусы төзелүне иглан иткән.

ГРЕЦИЯ--ИТАЛИЯ СУГЫШЫ

АФИНА, 25 декабрь. Греция телеграф агентлыгы Греция верховный командованиесенең түбәндәге сводкасын тапшыра: „Кичә җирле сугышлар вактында без күп итальяннарны плен алдык, шулай ук 8 пушканы һәм күп кенә сугыш материалларын кулга төшердек“.

„Пройа“ газетасы Италия гаскәрләренең Химараны ташлап китеп Валонага таба чигенеп баруларын хәбәр итә. Италия гаскәрләре Валоча тигезлегенә юл ача торган Логарас тирәсендә үзләренең позицияләрен ныгыталар. Тепелене районында итальяннар үз позицияләреннән чигенгәннәр.

БЕЛГРАД, 25 декабрь. „Политика“ газетасының язуынча, греклар Химараны алганнан соң анда кечрәк бер отряд кына калдырганнар. Гаскәрләрнең калган частьләре алга баруларында дәвам итәләр.

Кичә Тепелене районында грек гаскәрләре Италиянең Альп отрядларына каршы штык атакасына күчкәннәр. Үзәк фронтта грекларның һөҗүме аеруча кискен бара. Анда итальяннар берничә контратака ясаганнар.

Träger Поградец районында греклар берничә тапкыр Эльбасанга барып чыгарга тырышканнар, ләкин Италия оборонасы аларга һәр вакыт бик нык каршы торган. Итальяннарга Эльбасаннан ярдәмче көчләр китерелә торган юлны өзәргә омтылып, грек гаскәрләре Шкумба һәм Девол елгалары районында әһәмиятле берничә биеклекне алганнар.

Төньякта хәрәкәт итүче грек частьләре Тепелене — Клисура секторындагы гаскәрләр белән кушылу өчен көньякка таба баралар.

Салкыннар дәвам итүгә дә карамастан, Поградец — Клисура секторында бик каты сугыш бара. Монда итальяннар яңа көчләр китергәннәр. Һәр ике як кул гранаталары кулланалар. Әйтүләренә караганда, итальяннар Клисура якынында әһәмиятле бер стратегик позицияне һәм ике авылны алганнар. Греклар бу пунктларны кире кайтарырга маташалар.

НЬЮ-ЙОРК, 25 декабрь. Юнайтед Пресс агентлыгының Стругадагы (Югославия) хәбәрчесенең язуына караганда, 24 нче декабрьдә Греция һәм Англия самолетлары Бератны бомбага тотканнар. 9 кеше үтерелгән һәм 15 кеше яраланган. Берат аэродромына шактый зиан килгән. Тепеленедән һәм Клисурадан төньяктагы секторда греклар итальяннарның өч һөҗүмен кире кайтарганнар һәм контратакага күчкәннәр. 3 сәгать сугышканнан соң итальяннар төньякка, Вранииштидан төньякка таба 5 миль ераклыктагы Лепеникага чигенергә мәҗбүр булганнар. Чигенеп барганда итальяннар Шушика елгасындагы күперне җимергәннәр.

(ТАСС).

АФРИКАДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕНЕҢ БАРЫШЫ

ЛОНДОН, 25 декабрь. (ТАСС). Рейтер агентлыгы Каһирәдән Англиянең һава көчләре командованиесенең белдерүен тапшыра: „23 нче декабрьдә төнлә Англия авиациясе Кастель Бенитоны һәм Триполине бик нык бомбага тотты. Бомбалар Триполидәге аэродромга, бухтага, гидросамолетлар ангарына, электр станциясенә һәм башка хәрби объектларга ташланды. Бомбага тотудан бик күп янгыннар һәм шартлаулар булды. Таможня биналарына, молга һәм ангарларга бомбаларның туры төшкәнлеге күренде. Электр станциясен бомбага тотканда бер-бер артлы 9 шартлау булды. Бомбага тотудан бик күп ягулык юк ителде. Безнең самолетлар барсы да үз базаларына кайттылар“.

ЛОНДОН, 25 декабрь. (ТАСС). Фронттан алынган хәбәрләргә караганда, Англия көчләре итальяннарның оборона линиясе тирәсендә үзләренең позицияләрен туктаусыз ныгытуларында дәвам итәләр. Итальяннар да, үз чиратларында, бомбадан качу урыннары һәм окоплар казыйлар. Англичаннар итальяннарның позицияләрен өзлексез бомбага тотып торалар. Бомбага тоту торган саен көчәя бара.

ИТАЛИЯ СВОДКАСЫ

РИМ, 25 декабрь. (ТАСС). Стефани агентлыгы Италия командованиесенең түбәндәге сводкасын тапшыра: „Киренаики чигендә хәл үзгәрешсез. Һава берләшмәләре дошманның моторлаштырылган гаскәрләрен бомбага тотуны һәм аларга пулеметлардан атуны дәвам иттерделәр.

Триполитаниядә (Ливия) дошман Триполи шәһәрен һәм портын бомбага тотып, беркадәр зиан китерде.

Көнчыгыш Африкада, Судан чигендә, 23 нче декабрьдә безнең разведка отряды үзенә һөҗүм иткән броневикларны югалтулар белән чигенергә мәҗбүр итте.

Греция фронтында һаваның начар булуы операцияләргә комачаулады.

Кичә көндез дошманның бер самолеты Неапольгә һәм аның тирәләренә һөҗүм итеп, берничә яндыргыч граната һәм листовкалар ташлады.

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

— Бомбейдә „Гражданлык ирекләре союзы“ Һиндстанда ирекләрне кысуга каршы протест митингысы оештырган. Митингта кабул ителгән резолюция митингларда яки матбугатта сугышка каршы сөйләүләрне тыюга каршы протест белдерә.

— 22 нче декабрьдә Бангкокта (Таиның башкаласы) Япония белән Таи арасында дуслык турында шушы елның 12 нче июнендә төзелгән договорны ратификацияләү грамоталары алмашу булган.

— Шушы елның икенче кварталында Һиндстанда 101 забастовка булган. Аларда 268.580 эшче катнашкан. 31 забастовка эшчеләрнең җиңүе белән тәмам булган. 18 забастовка буенча эшчеләрнең таләпләре беркадәр канәгатьләндерелгән.

КЫРГЫЗ ҖЫРЧЫСЫ ТОКТОГЫЛ

Шушы көннәрдә кыргыз халкы үзенең талантлы улы—мәшһүр җырчы, композитор, виртуоз музыкант Токтогыл Сатылгановның тууына 75 ел тулу юбилеен бәйрәм итте.

Токтогыл Сатылганов лирикасы кыргыз поэзиясендә аеруча күренекле урын тота. Аның иҗады үзеннән алда җырлаган акыннар иҗадыннан искиткеч гадилеге, фикеренең ачыклыгы белән, аеруча лирикалылыгы, садәлеге белән аерылып тора.

⁂

Токтогыл 1864 нче елда Китмән Түбәдә Сатылган исемле фәкыйр мал игүче семьясендә туа. 8 яш тулгач та аны атасы бер байга көтүче малай итеп бирә. Кыргызстанның бай һәм матур табигате эчендә көтүче булып йөрү нәни Токтогылда поэзиягә бик тиз мәхәббәт тудыра. Җыр, поэзия—тау араларында ялгыз яшәүче көтүче малайның бердән-бер юлдашлары булып китәләр. Җәйләүдә көтү көтеп йөргәндә Токтогыл үзенең биренче җырларын иҗад итә. Һәм сонра халык бәйрәмнәрендә, күңел ачу җыеннарында сөекле уенчы, атаклы җырчы булып китә. Шулай итеп бик тиз арада яшь җырчының даны бөтен Китмән Түбә буенча тарала.

⁂

Ул чакларда кыргыз җирләрендә һәрбер эре манап үзенең сараенда акын асрый торган булган. Бу акыннар төрле бәйрәмнәрдә, табыннарда үзләренең манапларын мактап җырлый торган булганнар.

Манаплар Токтогылның талант көчен күреп аны да сарай җырчысы итмәкче булалар. Ләкин Токтогыл мондый такдимнәрне кире кага. Үзенең сөйгән халкына турылыклы булып калганы хәлдә, кыю һәм ирек сөючән җырларын җырлауда дәвам итә.

Үзләренең чирканыч уйлары барып чыкмаячагын белгәч, манаплар буйсынмас җырчыдан котылу юлларын эзли башлыйлар.

Юлы табыла. Аны баш күтәрүдә гаепләп кулга алалар. Башка каторжаннар белән бергә Үзбәкстан, Төркмәнстан аша Красноводск, Астрахань шәһәрләре аша Москвага китерәләр. Аннан Омск шәһәренең пересыльный төрмәсенә, аннан ел ярым дигәндә Иркутскига китереп җиткерәләр. Иркутскидан мәшһүр Александровский центральгә озаталар.

Юлда барганда Токтогыл кача. Ләкин ике айдан соң тотып китерелә. Аяк-кулларын тагын салкын тимер богау сырып ала. Ә качкан өчен тагы егерме ел каторга хезмәте өстәлә. Шулай итеп, кыргыз халкының сөекле шагыйре салкын Себердә салкын тимер богау белән уралган хәлдә яши башлый.

Бу—Байкал тимер юлын салу еллары була. Токтогылны шунда эшкә озаталар.

Токтогыл андагы авыр каторга хезмәте турында үзенең иҗадында бик күп җыр иҗад итә. Эштән арып караңгы, салкын төрмәгә кайткач туган илен сагынып җырлый.

⁂

Токтогыл тагы кача. Ә 1916 нчы елда янадан төрмәгә ябыла. Ләкин ирек сөюче кыргыз халкы үзенең сөекле җырчысының, агитаторының төрмәдә ятуы белән килешә алмый. Алар бик күп акча җыялар да Токтогылны порукага алалар.

Ләкин бу әле бөтенләй котылу булмый, бу бары тимер рәшәткәдән, авыр богаудан котылу гына була. Токтогылны түрәләр һаман күзәтеп, аның авызыннан чыккан һәрбер сүзгә колак салып торалар. Аның һәрбер сүзеннән гаеп табарга тырышалар. Токтогылны төрмәдән чын-чынлап бары Бөек Октябрь Социалистик Революция генә коткара.

Һәм тәмам котылган акын күңле белән Кремльгә карап киң сулыш ала да сазына чиртә-чиртә бөтен тавышына кычкырып җырлый башлый.

Җыр революция даһие Владимир Ильич Ленин турында була. Һәм бу җыр хәзергә кадәр кыргыз халык телендә йөри торган Ленин турындагы җырлар арасында иң садәсе, иң матуры, иң өстене булып санала.

Кыргызстанның Ленин орденлы Дәүләт Музыкаль театры кыргыз халкының атаклы акыны Токтогыл тормышыннан алынып язылган „Токтогыл“ операсын куйды. Рәсемдә: операның икенче картинасыннан күренеш. Токтогылны (уртада) һәм аның иптәше Сарыны кулга алу вакты.

А. Вахвалов фотосы (ТАСС).

Тактогыл революциядән соң бик күп җырлый. Ул җырлары белән авылдан авылга йөри. Аның гыйбрәтле җырларында намус белән эшләргә чакыру ишетелә. Аның җырларында бүгенге бәхетле тормыш симфониясенең көчле тавышы яңгырый.

⁂

Токтогыл 1933 нче елда үлә. Ләкин ул үлгәндә, тугандагы шикелле бәхетсез булмый. Ул халыкның хөрмәте, мәхәббәте эчендә, исменең һәм иҗадының мәңгелек һәйкәл булып калачагына ышанган хәлдә дөньядан китә.

⁂

Кыргыз халкына карата сүнмәс мәхәббәт, байларга, манапларга, түрәләргә, самодержавиегә, аның чиновникларына карата нәфрәт—Токтогыл иҗадының төп билгесе булып тора. Ләкин Токтогылның җырлары үзеннән алда яшәгән акыннарның иҗадларында еш очрый торган көчсез шикаять, йомшак зар түгел. Токтогылның җырлары җитәрлек кыюлар, үткен тешлеләр. Аның җырлары халыкны байларга, самодержавиегә каршы көрәшкә чакырып торалар. Эксплоататорларны фаш итәләр.

Ләгнәт төшсен саран байларга
Ярлы хакын алып калганга,
Һәм байдан да саран манапка
Санаганга кешене хайванга.

Токтогыл һәр вакыт оптимист. Ул һәр вакыт халык көченә ышана. Ул халыкның үзен коллыкта яшәтүчеләр белән бер көн исәп-хисабын өзәчәгенә, җир йөзенең хәшәрәтләрдән арыначагына ышана:

„Халык ул көчле ташкын күк
Ташып чыкса таулар җимерелер“—дип

җырлый.

Токтогылның чәнечкеле җырлары байларга, манапларга чәнчү белән генә чикләнми. Аның җырлары патша чиновниклары өстенә дә агулы ук булып очып бара. Бер тапкыр манаплар налог өчен кыргызларның актык нәрсәләрен талап ала башлагач, зур гаугә куба. Баш күтәргән халыкны манаплар белән килештерергә, буйсынырга чакыру өчен килгән патша чиновнигына карап Токтогыл шундый җыр җырлый:

Ярлы мескен инде нишләсен?
Актык сарыгын тартып алдылар.
Барсына да түзде мескен ярлы,
Балалары сөтсез калдылар.
Синең бар бит, түрә, кодрәтең
Таланганын кайтар ярлының
Ә турылык белми торган булсаң,
Әйдә,
Тигесен дә салдыр ярлының.

Ә каторгага җибәрү өчен богаулангач үзен тотып бирүче манапларга болай дип җырлый:

Илгә исән-сау каиталсам
Күзләренне чукып алырмын.
Илгә исән-сау кайталсам
Моның өчен үчем алырмын.

⁂

Токтогыл кыргыз халык шагыйре. Ул кыргыз халкының моң-зарларын җырлый. Ләкин ул үзенең иҗадында тар-милли темалар белән генә чикләнеп калмый. Ул үзенең һәр нәрсәдән мәхрум ителгән халкы турындагы җырларында интернациональ идеяләрне дә чагылдыра.

Үзбәк йөрәге дә минекедәй үк—
Хәсрәт белән тулы сагышлы.
Татарның да шулай, урысның да
Йөрәкләре кайгы сагышлы.
Күп тоткыннар күрдем мин алардан
Бик күбесе ачтан үлделәр...

Әйе, акынның йөрәге сагышлы була, акын кайгылы, хәсрәтле була. Ләкин ул бер кайчан да төшенке күңелле булмый. Төрмәдән качып, зур өметләр белән канатланып акын иленә кайта. Ләкин... улы үлгән була, хатыны башкага чыккан була. Ә йорты урнында җилләр исә. Аяныч хәл. Ләкин халкын өзелеп сөюе, халкының да аны шулай сөюе акынга җан кертә. Ул салынган башын күтәрә, изелеп төшкән гәүдәсен турайта да җырлый:

Сыкранудан мина ни файда,
Ятим калдым, дип түгел?
Ташламас әле илем,
Ташламас халкым минем.

⁂

Зур йөрәклелек, оптимислык Токтогылның һәр вакыттагы юлдашлары булалар. Токтогыл үлем алдында да калтыранып төшенкелеккә бирелми. Картайгач, үлеме якынайганны белгәч, ул картлыгыннан зарланмый, үләсеннән курыкмый, бары тик халкы белән аерылу күңелсезлеген күреп кенә борчыла.

Туктап калса тургай йөрәгем—
Сау бул инде сөйгән халкым,
Китәм бугай сезнең арадан,
Сау бул инде кыргыз халкы.

⁂

Октябрь Социалистик Революциягә кадәр күбесенчә кайгылы җырлар җырлап үткәргән Токтогыл революция булу белән шатлыклы тормыш җырчысы булып китә. Акын Владимир Ильич Ленин турындагы Октябрь революциясе турындагы җырларында үзенең шагыйрьлек талантының бөтен тирәнлеген ачып сала.

Котылу сәгатләре җиткәч,
Шатлыгымнан тиремә сыймадым.
Ленин азат итте халыкны,
Ленин өзде коллык богавын.
Сәлам, Ленин, кыргыз халкыннан,
Сәлам сиңа, изге туганым.

⁂

Токтогыл бәхет турында да күп җырлый һәм Токтогыл бәхет сүзен бик дөрес аңлый. Ул аерым кешеләрнең генә шат, рәхәт тормышларын бәхеткә санамый. Токтогыл бары хезмәт белән, көрәш юлы белән, бөтен халык теләге белән алынган бәхетне генә бәхет дип таный. Шуңа күрә дә ул кешегә иң югары бәһане бирә. „Дөньяда кешедән дә кыйммәтле нәрсә юк“ ди ул үзенең бер әйтемендә.

Токтогыл, кешене сөйгән шикелле үк, тормышны да сөя. Һәм бу—яшәүгә булган мәхәббәт, аңарда үлемгә карата килешмәүчән нәфрәт тудыра. Шуңа күрә дә Токтогыл үлгәнчегә кадәр зур дәрт белән яшьлек турында җырлый. Акын бу темага әледән-әле кайтып җырлый. Ул, картлыктан да, үлемнән дә көчлерәк бер кодрәт барлыкка ышана. Ул, халыкның бер кайчан да үлмәячәгенә, димәк иҗадының да бер кайчан да үлмәячәгенә ышана.

Яшьлек кайтмас, инде картайдым
Ә шулай да йөрәк яшь әле.
Картаймамын халкым телендә,
Мин мәңге яш килеш яшәрмен.

Токтогылның сүзләре дөрескә чыктылар. Ленин—Сталин байрагы астында коммунизмга баручы бәхетле кыргыз халкы зур мәхәббәт һәм ихтирам белән бөек җырчысын искә ала.

Токтогыл бүген иксез-чиксез илебезнең халыклары алдына азатлык сөюче шат күңелле Токтогыл сыйфатында килеп басты. Токтогылның исме Советлар Союзындагы иң яхшы шагыйрьләрнең алтын исемлегенә керде.

Г. Гобәй.

„Бәхетсез егет“ драмасында катнашучылардан бер төркем. Сулдан уңга: Гайни ролендә—РСФСР ның атказанган артисткасы Ф. Ильская, Закир ролендә—артист Ш. Шамильский, Кәрим бай ролендә—РСФСР ның атказанган артисты, орденлы З. Солтанов, Мәрьям ролендә артистка Камалова, Җәмилә ролендә—РСФСР ның атказанган артисткасы, орденлы Г. Болгарская иптәшләр.

УҢЫШЛЫ СПЕКТАКЛЬ

(„БӘХЕТСЕЗ ЕГЕТ“ ТУРЫНДА)

Татар Дәүләт Академия театры быел тамашачыларга Г. Камалның „Бәхетсез егет“ исемле драмасын күрсәтә башлады. Без моны тәбрикләп каршы алабыз. Бай эчтәлекле һәм зур осталык белән язылган „Бәхетсез егет“ драмасын театр үзенең репертуарына кертеп бик яхшы эшләгән. Г. Камал әсәрләренең киңрәк уйналуын халык театрдан күптән көтә иде инде.

Г. Камалның бу драмасында татар буржуаз җәмгыятенең череп таралуы, наданлыгы, ахмаклыгы драматик яктан оста эшләнгән картиналарда, бик характерлы образларда ачыла. Драматург ике буржуаз семьяне капма-каршы куеп гәүдәләндерә: берсе консерватив карашлы кадимче Кәрим бай семьясе, икенчесе — либераль бай Сәгыйт Сабитов семьясе. Комсыз, надан, байлыгы белән масайган Кәрим бай үзен бик мәртәбәле, алдынгы кеше итеп исәпли. Ул белем, культура турында да сөйләнеп куя. Драматург монын нинди „культуралы кеше“ икәнлеген берничә сыйфатын гына бирү белән үк бик оста итеп ачып сала. Кәрим байның өендә культура билгесе түгел, хәтта язу карасы да юк: карасы күптән кипкән, каләмнәре череп сынып беткән. Ул телеграммасын язганда да „пыштальйон үзе төзәтер“ гә калдыра. Үзенең улы Закир югалгач, аның турында кайгыртудан бигрәк, сәүдәсен кайгырта, артык расходлардан курка. Аның аталык хисенлә дә акча, байлык өстенлек итә. Драмада буржуаз мораленең капиталга, байлыкка нигезләнгәнлеге ачык күрсәтелә.

„Бәхетсез егет“ тә вакыйгаләрнен төеннәре Закирнын язмышы, хәле белән бәйләнгән. Закирның Гайнигә булган көчле мәхәббәте аны авыр, күнелсез хәлләргә алып кереп китә. Аның хисен бер кем дә аңламый, мәхәббәтен таптыйлар, аны алдыйлар. Закир бозыклык, караклык юлына төшә, аны буржуаз җәмгыят тудырган сазлык, бозыклык юк итә.

Шулай итеп, Кәрим байларның черек җәмгыяте кешене начар юлга кертә, ул яшләргә чын белем, тәрбия бирүгә дә сәләтле булмый.

Г. Камал „Бәхетсез егет“ тә ата-аналарның балаларга тәрбия бирү мәсьәләсен кискен куя, ләкин драма тәрбия мәсьәләсе белән генә чикләнми, зур социаль мәсьәләләрне чагылдыра, буржуа җәмгыятенең әшәкелеген, бозыклыгын фаш итә.

„Бәхетсез егет“не сәхнәгә куючы режиссер Сульва—Вәлиев һәм бөтен артистлар коллективы драмачың әнә шул төп фикрен, эчке драматик динамикасын дөрес аңлаганнар, һәм бытовой вак детальләрне натуралистик төстә кабарту белән мавыкмыйча, чын реалистик, җанлы спектакль тудырдылар. Бөтен постановкада драманың социаль эчтәлегенә басым ясап уйнау ачык сизелеп тора. Бу—бик яхшы. Югисә драмада куелган тәрбия мәсьәләсенә генә басым ясалган булса, драманы бер яклы гына аңлау килеп чыккан булыр иде һәм уен ла хәзерге көчендәгечә тулы яңгырамас иде.

Режиссер Сульва—Вәлиев бу постановкага шактый көч куйган. Уен ритмикасын, динамикасын йомшарта торган артык урыннарны кыскарту, озын монологларны диалогларга бүлү кебек режиссерның төзәтмәләре уңышлы гына эшләнгәннәр. Ләкин Закирның характерын тулырак ачуга ярдәм итә торган кайбер моментлар урынсыз кыскартылганнар. Төп оригиналда, өченче пәрдәдә Закир үзенең начар юлга кереп китүенең сәбәбен аңларга, гаепле кешеләрне табарга омтылып карый, баткаклыктан котылырга талпына. Ләкин, табигый ки, ул гаепле кешеләрен дә һәм котылу юлын да таба алмый. Ахырда түбәнгә, һәлакәткә таба тәгәрәп баручы Закир үзенең торган пычрак, караңгы бүлмәсенә карап бөтен тормышына ләгнәтләр әйтеп: „Карасана зинһар бу йортның каралыгын! Моның зинданнан кай җире аермасы бар! Бу зиндан гына түгел бу, кабер бу, кабер!“—ди.

Менә шундый кискен моментларны, герой трагедиясенең тирәнлеген характерлаган монологларны озын булган өчен генә сызып ташлау белән һич тә килешеп булмый. Уенны эчтәлеккә буйсындыру урнына, эчтәлекне уенга буйсындырырга ярамый.

Шулай ук драматургның әсәренә сүзләр өстәп ирекле „төзәтүләр“ белән лә килешеп булмый. Фахишә Гайнигә капиталистик җәмгыятне фаш итүче „акыллы сүзләр“ өстәлү аркасында Гайни образы драматург биргән характерыннан берникадәр үзгәреп киткән; Гайни Закирдан өстенрәк, үзенең әшәке эшләренең социаль нигезен аңлаган төсле булып чыккан. Г. Камалда исә мондый табигыйсезлек юк. Асылда бит Гайнигә „аңлы сүзләр“ әйттерү хәкыйкаткә лә каршы килә, Гайни ул „өстәмә“ сүзен әйтмичә дә бөтен драма буенча аның магнәсе аңлашыла. Г. Камал кебек художник белән исәпләшергә кирәк иде.

„Бәхетсез егет“тә артистлар үз рольләрен бирелеп, чын дәрт белән, иркен башкардылар. Моңарчы куелган кайбер пьесалар артистларның сәләтләренә киңрәк ачылырга мөмкинлек бирмәгәнлекләрен күрергә туры килгән булса, бу постановкада инде ул нәрсә сизелми. Артистлар өчен монда уйнарлык роль бар, типик характерны сәхнәдә тулы күрсәтү өчен оста драматург тудырган төгәл эшләнгән типлар бар. Бу постановкада артист белән драматург арасында кайчак булгалый торган кысынкылык, тарлык, ясалмалык күренми. Ә бу, спектакльнең уңышлы чыгуы өчен бик әһәмиятле момент.

Закир ролен башкаручы Шамильский тирән хисле, җанлы уены белән үзенең талантлы артист икәнлеген ачык күрсәтте. Аның уены табигый, ул геройның эчке кичерешләре дулкынын гаҗәп оста бирә белә. Бары тик дүртенче пәрдәнең башында гына Шамильскийның тавышы ышанычсызрак яңгырады һәм хәрәкәтләрендә дә бераз салмаклык сизелде; бу—бер төр стильдә уйналып килгән уенның ритмикасын берникадәр йомшарта төште. РСФСР ның атказанган артисткасы Ф. Ильская, роле бер пәрдәдә генә булуына карамастан, Гайни образын истә калырлык дәрәҗәдә бөтен характерлы сыйфатлары белән гәүдәләндерде. Ф. Ильская бу ролен иркен һәм җиңел башкарды.

Казан бае Кәрим (РСФСР ның атказанган артисты З. Солтанов), аның хатыны Җәмилә (РСФСР ның атказанган артисткасы Болгарская), Магри карчык (Татарстанның атказанган артисткасы Арапова), Уфа бае Сәгыйт Сабитов (Татарстанның атказанган артисты Уразиков), Кәримә (Басыйрова) образлары һәр кайсы нигездә үзенчәлекле характерлары белән ачылалар, тамашачыга җитәрлек дәрәҗәдә эшләнгәннәр. Болгарскаяның Җәмилә ролен, Арапованың Магри карчык ролен аеруча яхшы уйнауларын әйтеп үтәргә кирәк.

Сәхнәдә күп кенә уңышлы образлар тудырган З. Солтановның уйнавына аеруча тукталырга кирәк. Ул тупас бай ролен җидди, реалистик тонда уйный, бу образны тамашачыларга дөрес җиткерә. Ләкин бу урында аның бер кимчелеген әйтмичә булмый. З. Солтанов башкарган Кәрим бай образы бөтен үзенчәлекле яклары белән, элек без күргән Хәмзә бай һәм башкалардан аерылып торган индивидуаль яклары белән тиешенчә ачылды дип әйтеп булмый әле. Кәрим бай хәтта грим, костюмнары белән дә элек сәхнәдә күрсәтелгән шундый ук типлардан артык аерылып тормады.

„Бәхетсез егет“ бик кыска вакыт эчендә хәзерләнеп куелды. Шуңа күрә оформление дә, аерым детальләр дә, артистның вактыннан иртәрәк чыгып китүе, шәмнең сүнүе, кайбер артистларның аерым сүзләрне онытып, тотлыгып калулары кебек кытыршылыклар сизелүе аңлашыла торган хәл. Ләкин бу вак кытыршылыклар артистларның талантлы уеннары белән капландылар, күзгә артык бәрелеп тормадылар. Алар эш процессында төзәтелерлек кимчелекләр. Гомумән „Бәхетсез егет“ спектаклен тамашачылар зур канәгатләнү белән карыйлар.

Кызганычка каршы, артистларның яхшы уеннарына сәхнә оформлениесе, декорация гармонировать итеп тормый. Декорация төссез, артык саран эшләнгән, художникның иҗади эзләнүе, оригинальлеге сизелми. Бары тик өченче пәрдәнең оформлениесе генә уңышлы.

Ахырда шуны да әйтергә кирәк, без гадәттә Татар Дәүләт Академия театрының иҗад йөзе, юнәлеше, элек-электән сакланып үстерелеп килгән традицияләре турында бик аз уйланабыз, бездә театрның тәҗрибәсен өйрәнеп йомгаклау юк диярлек. Теге я бу постановканың социалистик реализм сәнгатен үстерүдә нинди адым ясавы, артистларның үсүләрен ничек чагылдыруы турында киңрәк фикер алышу кирәк булса, төпле дискуссия оештыру (театрда да, язучылар союзында да) практикасы бездә юк. Ә бу нәрсәләр турында күптән уйланырга вакыт инде. Бигрәк тә Москвада булачак татар сәнгате декадасына хәзерлек бурычлары шуны таләп итәләр. „Бәхетсез егет“ постановкасы уңае белән Татар Дәүләт Академия театрының иҗад йөзе турында киңрәк сөйләргә яхшы нигез бар.

Хәсән Хәйри.

РЕДАКЦИЯГӘ КИЛГӘН ХАТЛАРДАН

КОЛХОЗНЫ АРТКА СӨЙРӘҮЧЕЛӘРГӘ КАРШЫ КӨРӘШМИЛӘР

Кызыл Армия районы, Ворошилов исемендәге колхозда җитешсезлекләр бик күп. Бу колхозда социалистик милекне әрәм-шәрәм итүләргә һәм югалтуларга каршы көрәш оештырылмаган. Колхоз членнары арасында хезмәт дисциплинасы бик түбән. Колхоз производствосында эшләүдән баш тартучыларга карата артель уставы нигезендә чара күрелми. Колхоз члены Долгова 1940 нчы елның 11 ае эчендә 28, Корнятова 15, Зурбашева 45 һәм Горшкова бары 6 гына хезмәт көне эшләгәннәр. Новикова ел буена бер генә хезмәт көне дә эшләмәгән.

Колхозда учет эшләре буталган. Колхозчыларның хезмәт көннәре үз вактында кенәгәләргә язылмыйлар. 3 нче һәм 4 нче бригадаларда бу эш аеруча начар тора.

Колхозның атларыннан теләсә кем теләсә ничек файдаланып, күп кенә атларны эшкә яраксыз хәлгә китерәләр. Соңгы ике ай вакыт эчендә генә дә 8 бия колын салды.

Исаева Мария колхоз кырыннан 5 килограмм борчак һәм 80 килограмм чөгендер урлап тотылган иде. Бу турыда акт төзелеп район милициясенә бирелсә дә, район милициясе работнигы иптәш Хәйруллин „судка бирерлек фактлары юк“ дип, актны колхоз правлениесенә кире кайтарды. Ләкин колхоз правлениесендә Исаеваны җавапка тарту турында уйлап та караган кеше юк әле.

Быел җәй көне күп кенә колхозчылар кыр эшенә йөрмичә колхоз болыныннан печән чабып үзләренең өйләренә ташыдылар. Бу печәннәрне колхозга җыеп алу турында район прокурорыннан санкция булуга карамастан, колхоз председателе Мельников аларны җыеп алу чарасын күрми.

Ш. Закиров.

УРМАН КИСҮ ҺӘМ ТАШУ ПЛАНЫ ҮТӘЛМИ

Беренче Май районының кайбер авыл советы башкарма комитетларының җитәкчеләре урман кисү һәм аны ташу мәсьәләсенә гафу ителмәслек җавапсыз карыйлар. Мәсәлән, „Азат“, „Урал“, „Ирек“ „Кызыл Йолдыз“, „Кызыл Нур“, „Бүләк“ һәм башка күп кенә колхозлар шушы вакытка кадәр урман кисү эшенә керешкәннәре юк. Шунын нәтиҗәсендә урман кисү буенча Татарстан Совнаркомы тарафыннан төшерелгән план район күләмендә 18 процентка һәм ташу планы бары тик 11 процентка гына үтәлгән.

Урман кисү һәм ташу эшен өзеклеккә алып баручыларга карата район җитәкчеләре ашыгыч чаралар күрергә тиешләр.

С. Абдрахманов.

ДЕПУТАТ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларга бер ел тулуны совет халкы гаять зур шатлык һәм күтәренкелек белән билгеләп үтте. Дәүләт белән идарә итү эшенә тартылган күп меңләгән депутатлар—халык хезмәтчеләре бу көнне үз сайлаучылары белән очраштылар, үзләренең мактаулы депутатлык эшен ничек үтәүләре турында сайлаучылар алдында отчет бирделәр һәм киләчәктәге эшләренә яңа наказлар алдылар.

Шундый ук кызыклы очрашу 25 нче декабрьдә, 4 нче номерлы ясалма каучук заводы клубында да булып узды. ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе, хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы депутаты иптәш Динмехәметов үз сайлаучылары алдында отчет бирде. 400 дән артык кеше катнашы белән үткән бу җыелыш зур сөшканлык белән үтте.

Доклад өчен сүз ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш Динмөхәметовка бирелә. Ул, хезмәт ияләре депутатларының җирле советларына сайлаулардан соң үткән бер ел эчендә бөек социалистик илебез яулап алган казанышлар турында сөйли. Бу чорда илебезнең халык хуҗалыгын тагын да ныгыту һәм алга җибәрү буенча партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан күрелгән чаралар турында киң рәвештә тукталa. Ул бу турыда завод мисальләреннән дә күп кенә фактлар китерә.

— Хезмәт дисциплинасын ныгыту, продукциянең сыйфатын яхшырту турында һәм хезмәт резервлары турында СССР Верховный Советы Президиумы Указлары социалистик халык хуҗалыгын тагын да ныгытуда көчле корал булып тора,—ди иптәш Динмөхәметов. Моны ул завод-фабрикалар мисалендә конкрет фактлар белән раслый. Шуннан соң ул завод коллективын—үз сайлаучыларын киләчәктә тагын да яхшырак эшләргә, партиябез һәм хөкүмәтебез заданиеләрен намус белән үтәү өчен большевистик көрәшкә чакыра. Җыелыш аның бу чакыруына бердәм рәвештә көчле алкышлар белән җавап бирә.

Доклад буенча фикер алышуларда чыгып сөйләүче иптәшләр завод алдында торган бурычларны үтәү буенча завод коллективының бердәм көрәшен чагылдырдылар.

— Без, киләчәктә тагын да яхшырак эшләрбез. Күп санда һәм югары сыйфатлы продукция бирү белән социалистик Ватаныбызның экономик һәм оборона куәтен тагын да ныгытырбыз. Партиябезнең XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясен үз эшебездә яңа уңышлар белән билгеләрбез,—ди иптәш Бушмарин. Аның бу сүзләре завод коллективының бердәм теләге булып яңгырады.

К. Б.

Яңа ел алдыннан

Дәүләт сәүдәсе работниклары клубы яңа елны күңелле итеп каршылауга хәзерләнә. Клубның заллары матур итеп бизәлә, елкалар куела. 31 нче декабрьдә һәм 1 нче январьда яңа ел бәйрәменә багышланган кичәләр үткәрелә. Кичәләргә килүчеләргә һәр төрле костюмнар биреп тору өчен прокат пункты оештырылды. Иң кызыклы костюмнарда килүчеләргә призлар биреләчәк.

Клубның үзешчәнлек сәнгате көчләре тарафыннан концертлар биреләчәк. Тынлы һәм джаз-оркестрлар уйнап торачак. Кичәләр вактында фото-карнавал эшләячәк.

31 нче декабрьдән алып 5 нче январьга кадәр клубта балалар өчен елка бәйрәме үткәрелә.

⁂

Казан шәһәренең Белинский исемендәге 19 нчы номерлы урта мәктәбендә укучыларның ата-аналары кышкы каникулларны культуралы итеп үткәрү өчен зур ярдәм күрсәтәләр. Ата-аналарның көчләре белән шушы көннәрдә КИИКС залында мәктәп файдасына концерт бирелә. Укучыларның аналарыннан Попова, Бальчина, Зарова һәм башка иптәшләр яңа ел елкалары оештыруга актив катнашалар.

Мәктәптә үзенә махсус клуб бар. Клуб идарәсе председателе итеп 10 нчы класс отличнигы Галина Андреева сайланды. Балаларны үзешчәнлек сәнгатенә өйрәтү өчен клуб янында 42 түгәрәк төзелде, балаларның ата-аналары ярдәме белән курчак театры оештырылды.

„Степан Разин“ операсын радио аркылы тапшыру

Татарстан Радиокомитетының музыка секторы радио тыңлаучыларны совет опера композиторларының әсәрләре белән таныштыру өчен композитор А. Касьяновның „Степан Разин“ операсыннан өзекләр тапшыруны планга кертте.

Бу опера XVII нче гасырда изелгән халык массаларының Степан Разин җитәкчелегендә восстание ясауларын күрсәтә.

Радиокомитет бу операны музыкаль-әдәби монтаж белән тапшыра. Аның әдәби монтажы шагыйрь Н. Бирюков һәм В. Каменский тарафыннан язылды. Опера январь аенда тапшырылачак. Операда төп рольләрне башкару опера театры артистларыннан Н. Рудаков, А. Пустоветов һәм башка артистларга тапшырылды. Операның музыкасына җитәкчелек итүдә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе С. Бергольц катнашачак.

В. Е.

Экзаменнар сессиясе алдыннан

Казан Дәүләт Медицина институтында кышкы экзаменнар сессиясе 6 нчы январьда башлана. Институтта экзаменнар сессиясенә зур хәзерлек алып барыла. Студентлар өчен профессорлар һәм доцентлар тарафыннан консультацияләр оештырылды, экзаменнарга хәзерлек өчен кафедраларда, клиникаларда студентларга уңайлы шартлар тудырылды.

Сталин исемендәге стипендияне алучылардан Абдурафиков, Камашева, Чудина һәм Гуляева иптәшләр практик курсларны үттеләр һәм экзаменнарны срогыннан элек тапшырырга хәзерләнәләр. Уку отличнигы иптәш Н. Сиражеттинов марксизм-ленинизм нигезләре фәне буенча экзаменны отличнога тапшырды. Ул хәзер микробиология фәне буенча экзамен тапшыруга хәзерләнә.

С. Камал.

КЫСКА ХӘБӘРЛӘР

— Чистай шәһәрендә известь заводы төзүгә хәзерлек башланды. Төзү материаллары хәзерләү бара. Завод 1941 нче елда эксплоатациягә биреләчәк һәм ел саен 2000 тонна известь эшләп чыгарачак. Заводны төзү 97 мең сумга төшә.

— Сарманда „Җир шары әйләнәсе буйлап беренче сәяхәт“ дигән темада лекция булды. Сармандагы урта мәктәпнең география укытучысы иптәш Тимергалин тарафыннан укылган бу лекция зур игтибар белән тыңланды. Лекциягә 310 кеше килде.

— Биләрдә көксагыз буенча агротехниклар һәм кырчылык бригадирлары өчен 6 көнлек курслар үткәрелде. Курсларда 44 кеше укыды.

— Теләче районының „Төрек-баш“ колхозында Осоавиахим членнарыннан 27 кеше 115 сәгатлек программа буенча хәрби хәзерлек үтә. 40 сәгатлек занятие үткәрелде инде. Хәзер ату һәм чаңгыда йөрү буенча күнегү занятиеләре бара. Занятиеләр урманда һәм кырда үткәрелә.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

Бәхетсе леккә очрау. Билгесез бер ир кеше 9 нчы маршрут трамвай вагонының сул яктагы баскычына менеп баскан. Трамвай вагоны Кремль янында Казанка күперенә борылган вакытта билгесез кешенең башы телеграф баганасына бәрелгән. Ул шунда ук егылып төшеп үлгән. Гәүдәсен анатомия театрына җибәргәннәр.

— Андрей Карноухов дигән шофер 7—59 нчы номерлы автомобиль белән Кизица урамыннан барган чагында 10—11 яшләр чамасындагы билгесез бер малайны таптатып каты яралаган. Малайны авыр хәлдә 5 нче номерлы больницага китергәннәр. Шофер җавапка тартыла.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответственный редактор
Х. АБДРАХМАНОВ.

Татар Дәүләт Опера театры
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
Бүген
ЧИО-ЧИО-САН
28 нче декабрьдә
ХОРЕОГРАФИК КОНЦЕРТ

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
29, 30 һәм 31 нче декабрьдә кич
Г. Камал әсәре
БӘХЕТСЕЗ ЕГЕТ
Билетлар сатыла.

Зур Драма Театры
Бүген һәм 28 нче декабрьдә
соңгы тапкыр
БОЗЛАР ПЛЕНЛЫГЫНДА
29 һәм 31 нче декабрьдә
АНДЖЕЛО
Билетлар сатыла.

„ГЛАВКИНОПРОКАТ“ НЫҢ
Татарстан конторасы экраннарга
„Яков Свердлов“

дигән зур тарихи-биографик фильм чыгара.
Атказанган сәнгат эшлеклесе С. Юткевич постановкасы.
В. И. Ленин ролендә РСФСР ның атказанган артисты Штраух.
И. В. Сталин ролендә артист С. Кобаладзе.
Я. М. Свердлов ролендә РСФСР ның атказанган артисты орденлы Л. Любашевский.
Фильмдә орденлы артистлардан Н. Крючков һәм Н. Охлопков катнашалар.
2505-3-2

КИИКС РАБФАГЫ
кичке бүлекнең III һәм IV курсларына
өстәмә рәвештә
СТУДЕНТЛАР АЛА
Уку — түләүсез. IV нче курс студентларына стипендия бирелә.
Гаризалар кич 5 тән 10 сәгатькә кадәр алына. К. Маркс урамы, йорт № 70. КИИКС.
ДИРЕКЦИЯ.

Дәүләт циркы
БҮГЕН ҺӘМ ҺӘР КӨННЕ
ЧЕГӘН аттракционының цирк уеннары һәм күп кенә башка номерлар.
АМИНЫҢ (Трофимовның) берничә генә гастрольләре. Әйләнеп тора торган дирижабль әйләнәсендә планерда очу.

КУЛЬТУРА САРАЕ
(Киров районы)
28 һәм 29 нчы декабрьдә
ГАЛИЯБАНУ
Билетлар сатыла.

БҮГЕН КИНОЛАРДА:

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	БИШЕНЧЕ ОКЕАН
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	Яңа художестволы фильм Кайту
16 яшькә кадәрге балалар кертелми.	
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 4-30, 6, 8, 10 да.	СОҢГЫ ТӨН
„ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 5, 6-30, 8, 10.	ГЕРОЙНЫҢ ЭНЕСЕ
„Колхозник“ 4, 6, 8 һәм 10 да	КАЙТУ
16 яшькә кадәрге балалар кертелми.	
„ЧАТКЫ“ 4, 6, 8 һәм 10 да	МОРЯКЛАР
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	МУЗЫКАЛЬ ВАКЫЙГА
КУЛЬТУРА САРАЕ 4, 6, 7-30 һәм 9-30 да.	ЦИРК

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Каз. н, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: пропаганда бүлеге һәм экономик бүлек 18—22, секретариат 5—86, партия бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, төнге редакция 3—75, типография 33—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ПФ 3584 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ. 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 5534.